• ӘҢГӘМӘ •

**СПОРТ ҺӘМ ИСЛАМ ДИНЕ**

*Актив рәвештә спорт белән шөгыльләнү исламга каршы киләме?*

*5 бит*

• ВӘГАЗЬ •

**МӨХӘРРАМ АЕ ҺӘМ ГАШУРӘ КӨНЕ**

*Һиҗри ел буенча яңа 1440 ел якынлаша*

*6-7 бит*

• СОРАУ-ҖАВАП •

**ТӨШКӘ КИЛӘЧӘК КЕРСӘ...**

*Кеше төшендә киләчәктә булачак вакыйгаларны күрә аламы?*

*11 бит*

• БУ КЫЗЫКЛЫ •

**ҖӘБРАИЛ *галәйһис-сәләм* САТКАН ДӨЯ**

*Изгелек кылу – Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм сөннәте*

*12 бит*

*№ 8 (277)* *Татарстан мөселманнары диния нәзарәте басмасы* *зөлкагъдә – зөлхиҗҗә 1439*

*Август, 2018*

# دين ومعيشت

# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ



# Әссәламүгаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү!

## Мөхтәрәм дин кардәшләрем

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән сезне Гыйд әл-әдха – Корбан бәйрәме белән тәбриклим!

Корбан бәйрәме – бөек бәйрәм. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе: «Аллаһы Тәгалә каршында иң яхшы көн – Корбан бәйрәменең беренче көне», – дип әйткән. Корбан бәйрәменең тарихы Ибраһим пәйгамбәр вакыйгасы белән бәйле, ул Аллаһы Тәгаләнең әмеренә буйсынып үзенең күптән көтеп алынган улын корбан итәргә әзер була. Әмма Бөек Зат – Рәхимле һәм Гадел. Ибраһим галәйһис-сәләмнең итагатьле булуына инанып, Ул болай ди: «Бу – сынау иде! Син аны уңышлы уздың». Шуннан Раббыбыз Ибраһим галәйһис-сәләмнең улын корбан итү урынына корбанлык малын кабул итеп ала һәм аны тагын бер баланың дөньяга килүе белән бүләкли. Моннан Аллаһка якын булу өчен, кешенең корбан булуы таләп ителми, әмма Аллаһның кушканнарын берсүзсез үтәү һәм хакыйкать юлында үз-үзеңне аямыйча хезмәт итү соралганы аңлашыла. Шуның өчен дә Гыйд әл-әдха бәйрәмендә без шатлык, игелек һәм бәхет өләшергә, сәдака бирергә, мохтаҗларга корбан итен тапшырырга, ә иң мөһиме – Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын алырга тиеш.

Раббыбызның безнең корбаннарыбызны, хаҗиларыбызның хаҗларын кабул итүен һәм барысының да туган җирләренә исән-сау әйләнеп кайтуларын телим! Бәйрәм белән, хөрмәтле мөселман кардәшләребез!

**Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин**

# Казан дин әһелләре ГТО нормативларын үтәделәр





31 нче июль көнне Казан шәһәре имамнары республикабыз мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә Вахитов районының «Трудовые резервы» стадионына җыелды. Бирелдә алар беренче тапкыр «Хезмәткә һәм оборонага әзер» Россиякүләм физкультура-спорт комплексы сынау нормативларын тапшыруда катнаштылар. Бу – Казан мөхтәсибәте вәкилләренең беренче сессиясе, республика имам-мөхтәсибләре исә беренче сессияне быелның июнь аенда Чистайда үтәгән иделәр.

Чара Коръән аятьләрен уку белән башланып китте. Шәһәр дин әһелләрен Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, МАУ СОК «Трудовые резервы» директоры Руслан Минабетдинов, Татарстан Республикасында РОО «ГТО» рәисе Эдуард Иванов, Казан шәһәре Башкарма комитеты вәкиле Илнур Шакиров сәламләде, чарада массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашты.

Шәһәр имамнары үзләренең физик әзерлекләрен җиңел атлетика, көчне сынау гимнастикасы һәм сыгылмалык буенча сынады: урта дистанциягә йөгерү (ике километрдан өч километрга кадәр), тартылу, күтәрелү, сикерү, 60 метрга йөгерү.

ГТО нормативларын үтәүдә 22 яшьтән алып 70 яшькә кадәрге Казаннан 65 имам катнашты.

■ **dumrt.ru**

# «Хәләл» комитетын Ирек хәзрәт Җиһаншин җитәкләде

23 июльдән Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте карары белән Ирек хәзрәт Җиһаншин «Хәләл» стандартлары буенча комитет Рәисе итеп билгеләнде.

Бүгенге көнгә кадәр Ирек Җиһаншин Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фондының генераль директоры булып эшләде. Фондны ул 2016 елдан бирле җитәкләде.

Ирек хәзрәт «Мәрҗани» мәчете имамы, Россия ислам университеты проректоры, «Хәләл» стандартлары буенча комитет Рәисе урынбасары һәм Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең беркетмәләр бүлеге мөдире булып эшләде.

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте каршындагы «Хәләл» комитеты 2005 елда хәләл продукция җитештерүгә контрольдә тоту һәм алга этәрү максаты белән оештырылды.

# Апанай мәчетендә Вәлиулла Якупов музее ачылды

19 нчы июль Казанда татар дин әһеле, тарихчы һәм җәмәгать эшлеклесе, Апанай мәчетенең имам-хатыйбы Вәлиулла хәзрәт Ягъкубны (1963-2012) искә алу булды. Казан мөселман зиратында танылган дин әһеле кабере янына аның белән бергә эшләгән хәзрәтләр җыелды.

Шулай ук көннең беренче яртысында өйлә намазына кадәр Апанай мәчете бинасында Вәлиулла хәзрәткә багышланган музей ачылды. Чарада Җәлил хәзрәт Фазлыев, имамнар, җәмәгать эшлеклеләре катнашты.

■ **dumrt.ru**



# Татарстан мәчетләре арасында футбол ярышы үтте

11 нче август көнне Бөгелмә Татарстанның төрле почмакларыннан кунаклар кабул итте. Җыелуның сәбәбе – Татарстан мәчетләре арасында Бөгелмә муниципаль районы башлыгы Кубогына футбол буенча республика турниры. Ярышлар шатлыгын уртаклашырга һәм катнашучыларга көч бирергә Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин, ТР Президент аппараты вәкилләре, имамнар һәм мөхтәсибләр килде. Шәһәрнең мактаулы кунаклары шулай ук яңа Бөгелмә мәчете төзелешенә беренче таш салу тантанасында катнаштылар. Шунысы куанычлы, проект буенча мәчет янәшәсендә мәхәллә халкы өчен спорт комплексы булдыру да күздә тотыла.

Татарстан мәчетләре арасында футбол буенча Республика турнирын оештыручылар – Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Бөгелмә шәһәре һәм Бөгелмә районы мөхтәсибәте. Икенче тапкыр уза торган турнирда шәригать кануннарын үтәүче һәм биш вакыт намаз укучы уенчылар җыелды. Әлеге ярышларда Казан, Чаллы, Түбән Кама, Мамадыш, Чистай, Бөгелмә һәм башка районнарның командалары көч сынашты. Алар арасында иң яхшылары булып түбәнка-малылар, кукмаралылар һәм бөгелмәлеләр танылды. Төп бүләк «нефтехимия башкаласы»на китте. Шулай ук башка катнашучыларны да кыйммәтле бүләкләр һәм призлар белән бүләкләделәр. Моннан тыш, уен нәтиҗәләре буенча иң яхшы тренер, яхшы сакчы һәм яхшы һөҗүмче ачыкланды.

■ **dum.rt**

# Зәйдә VI Ялчыгол укулары

8 август көнне Зәйдә алтынчы мәртәбә Ялчыгол укулары узды. Чара күренекле татар мәгърифәтчесе, дин эшлеклесе, галим, язучы Таҗетдин Ялчыгол тормышына һәм иҗатына багышланган «Татар дөньясының күренекле вәкиле» фәнни-гамәли республикакүләм конференциясе Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм башка мәртәбәле кунаклар катнашында узды. Алар арасында – Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, профессорлар Хатыйп Миңнегулов һәм Фоат Галимуллин, имамнар, тел һәм әдәбият белгечләре, татар зыялылары. Барлыгы 200 кеше. Күркәм чара Имәнлебаш авылы зиратында бөек татар мәгърифәтчесенең каберен зиярәт кылудан башланды. Кунаклар галим рухына дога укыды.

Конференция үз эшен Имәнлебаш авылы Мәдәният йортында дәвам итте. Бирелә Ялчыгол тормышына һәм иҗатына багышланган күргәзмә оештырылган иде. Укулар рәсми рәвештә Коръән Кәрим аятьләрен укудан ачылып китте. Кунакларны Зәй районы башлыгы Разиф Кәримов сәламләде. Ул районда танылган татар дин галиме Таҗетдин Ялчыголның тормыш юлы, иҗатын, мирасын өйрәнү, саклау һәм аңа карата кызыксыну уяту буенча башкарылган эш турында сөйләде. Мисал өчен, шәһәрнең җәмигъ мәчете галим исемен йөртә, шулай ук Ялчыгол исемендәге музей һәм мәдрәсә дә эшләп килә. Ялчыгол укуларында катнашучыларга Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин дә мөрәҗәгать белән чыкты.

- Рухи тормышыбызның төрле якларына багышланган хезмәтләр язып калдырган Таҗетдин Ялчыгол, дөрестән дә, чып-чын халык вәгазьчесе булган, ул авылларда бик күп йөргән, Ислам диненә өндәгән, – диде Камил хәзрәт. – Аның «Тәварихе Болгария» китабы татар халкының тарихын ачып сала һәм халкыбыз ислам динен Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм безнең җирләргә җибәргән сәхабәләр кулыннан кабул итүе турында сөйли. Язучының иң киң таралган хезмәте исә – «Рисаләи Газизә» китабы. Әлеге китап беренче тапкыр 1847 елда Санкт-Петербургта нәшер ителә, ә аннары 1850 елда – Казанда, соңрак ул 40 тапкыр төрле тиражлар белән басыла, Идел буе–Урал төбәкләрендә тарала. Аның иң зур казанышы шунда ки, ул безгә исламга чакыруның иң үтемле һәм күркәм чаралары һәм үрнәкләрен күрсәтә. «Рисаләи Газизә», дөрестән дә, һәр мөселман кешесенең шәхси китапханәсендә булырга тиешле хезмәт».

Камил хәзрәт шулай ук дин галимнәренең шәҗәрәләре турында куертылучы бәхәсләргә карата да үз фикерен белдерде. «Фәнни даирәдә һәм интернет челтәрендә соңгы елларда Таҗетдин Ялчыголның шәҗәрәсе турында сүз куерталар. Башкортлар аны үзенеке дип саный, без, табигый ки, татар галиме дип исәплибез. Әлбәттә, һәркем үзенең генеологик чылбырында күренекле кешеләрнең булуын тели. Әмма без бүген Таҗетдин Ялчыгол кебек олпат галимнәрнең оныклары булырга лаек буын микән соң, дип уйлаучы юк, кызганыч. Без Шиһабетдин Мәрҗани, Галимҗан Баруди һәм башка татар галимнәренең рухи мирасына туры киләбезме, аларның китапларын укыйбызмы, аларның васыятьләренә һәм нәсыйхәтләренә колак салабызмы? Әгәр шулай икән, әлхәмдүлилләһ, без барыбыз да аларның буынын дәвам итүчеләр, чөнки ислам дине безнең калебләребезне һәм җаннарыбызны бәйләде. Әгәр юк икән, кан ягыннан якын булу бернигә дә тормый», – диде Татарстан мөфтие.

Конференция кысаларында шулай ук Җәлил хәзрәт Фазлыев, профессорлар Хатыйп Миңнегулов һәм Фоат Галимуллин, тарихчы Рәисә Муллахмәтова, язучы Рөстәм Галиуллин, Зәй мөхтәсибәтенең аксакаллар шурасы рәисе, Ялчыгол укуларын башлап җибәрүче Сәгыйть хәзрәт Камалов, татар мәгърифәтчесенең нәселе вәкиле Гамир Таҗетдинов һәм башкалар чыгыш ясадылар. Алар Ялчыгол иҗатының төп тенденцияләрен, тормышының билгеле булмаган якларын, калдырган фәнни, дини, әдәби мирасының әһәмиятен ачтылар.

VI Ялчыгол укулары Имәнлебаш авылы мәчетендә җәмәгать белән өйлә намазын уку белән тәмамланды.

Гарәп, фарсы һәм төрки телләрен, Шәрык гыйлемнәрен һәм мәдәниятен яхшы белгән, дөнья гизгән Таҗетдин Ялчыгол – төрле тармакларда эшләгән энциклопедик табигатьле кеше. Ул халыкны белемле, тәрбияле, динле итүгә үзеннән зур өлеш кертә. Аның китаплар күчерү, шәрехләү белән шөгыльләнүе дә мәгълүм.

Таҗетдин Ялчыгол тарих, әдәбият, фәлсәфә, тыйб, фикһ, илаһият һәм кайбер башка тармаклар буенча дистәдән артык китап язган: «Хәдиселбаб», «Кафия...», «Тәнбиһел–гафилин» («Ваемсызларны искәртү»), «Гыйльми табиб» һ.б. Болар арасында фән һәм мәдәният өчен аеруча икесе игътибарга лаек. Чөнки алар элек-электән укылып, өйрәнелеп килә. «Тәварихы Болгария» (1805 – аны кайчак «Тәварихы Болгар» дип тә йөртәләр.) – жанры белән шәҗәрәи, ягъни нәсел–нәсәбне гәүдәләндергән ядкәр.

Әдипнең икенче күренекле әсәре – чәчмә һәм тезмә юллар белән язылган, зур күләмле «Рисаләи Газизә» ядкяре (1806). Ул тәүге мәртәбә 1847 елда Санкт-Петербургта басылып чыккан (372 бит). Аннан соң Казанда күп тапкырлар дөнья күргән. Кульязмалары да шактый. Халык яратып укыган. Хәтта мәктәп-мәдрәсәләрдә башлангыч сыйныфларда дәреслек итеп файдаланганнар, балалар әдәбияты үрнәге итеп каралган. Аның гаять популярлыгына бер мисал: Тукай үзенең «Исемдә калганнар» әсәрендә «Кырлай авылыннан Җаек каласына алырга килгәндә мин ян тәрәзә төбендә «Рисаләи Газизә» укып утыра идем», - ди.

«Рисаләи Газизә» – Урта Азиядә яшәгән, чыгышы белән татар булган атаклы Суфый Аллаярның (1616 -1713) «Сөбател – гаҗизин» («Көчсезләрнең нык-лыгы») әсәренә шәрех. 2014 елда Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты әлеге хезмәтләрнең яңа басмаларын әзерләп бастырды һәм укучыларга тәкъдим итте.

■ dum.rt






# Кеше «нәфес»е һәм аның 7 баскычы

Гарәп телендә «нәфес» җан, кешенең тәне, каны, бөеклеге, нәрсәнең булса да асылы мәгънәсендә кулланыла. Тәсаувыфта «нәфес» – хисләрне, ихтыярны һәм тормышчанлык көчен үз эченә алган субстанция буларак билгеле.

Коръәндә «нәфес» сүзе ике төрле мәгънәдә килә. Беренче очракта, «нәфес» сүзе үз-үзеңне белдерү өчен кулланыла. «Нәфес»не «кешенең үзе» яки «җан» дип тәрҗемә итеп булыр иде. Коръән Кәримдәге Аллаһы Тәгаләнең сүзләре моның ачык мисалы булып тора.

**«Түбәнчелек һәм курку белән эчеңнән генә Раббыңны зекер ит һәм сөйләшүдә кычкырудан түбәнрәк тавыш белән зекер ит, иртәләрдә вә кичләрдә гафилләрдән булма!»**

«Әгъраф / Пәрдә», 7:205

Нәфеснең икенче мәгънәсе Коръәндә ешрак очрый һәм ул түбәнчел теләкләр, инстинктлар хас булган үзебезнең үзенчәлекле бер өлешебезне аңлата. Аңа усаллык, көчле теләк хас. Аны шулай ук җенси теләк дип тә атап була.

Нәфес – Аллаһы Тәгалә тарафыннан барлыкка китерелгән нечкә субстанция. Кешенең тәненә үтеп кергәнче нәфесне җан – рух, ә инде рух Аллаһы Тәгаләнең әмере белән тәнгә үтеп кергәч, аны нәфес дип атыйлар. Нәфес – тәннең җан белән кушылуыннан барлыкка килгән кешенең эчке дөньясы.

Асылда, кешеләрнең җаннары намуслы. Җан кешеләрнең тәненә алар ана карынында булганда ук кереп урнаша. Бу чынбарлык Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мәшһүр хәдисеннән дә билгеле: «Дөреслектә, һәрберегез ана карынында кырык көн орлык тамчысы булып, шул кадәр ук вакыт оешкан кан булып, аннан шуның кадәр үк ит кисәге булып оеша. Аннары аның янына фәрештә килеп җан өрә. Аңа (фәрештәгә) дүрт төрле нәрсәне язарга боерыла: баланың ризыгын, гомер озынлыгын, эшләрен, бәхетле яки бәхетсез булачагын» (Бохари, Мөслим).

Җан (рух) тәнгә урнашкач, кеше (инсан) дип аталган Аллаһы Тәгаләнең күркәм мәхлугы барлыкка килә. Барлык китаплар һәм барлык пәйгамбәрләр дә әнә шул кешенең җанын саклап калыр өчен: кешенең нәфесен камилләштерер өчен җибәрелгәннәр.

Кешенең нәфесенә шәһвәт (җенси теләк), гамьсезлек хас. Мондый тискәре сыйфатларның барлыкка килүенә тирәлек тәэсир итә. Әлеге тискәре факторлар кешене гөнаһлар кылырга этәрә. Әлбәттә, гөнаһлар эзсез генә узмыйлар. Алар кеше күңеленә тирән яра салалар. Кеше гөнаһ кылырга этәргән нәрсәләрдән арынып, яхшы якка үзгәрә. Нәфесен йөгәнли, тәүбә кыла, Аллаһка якыная. Үз нәфесеңне контрольдә тоту (йөгәнләү) ул үз теләкләреңнән һәм хыялларыңнан, ачуыңнан өстенрәк булып, сабырлык кылу дигән сүз.

Кешенең беренче һәм иң явыз дошманы – аның нәфесе. Ни өчен? Чөнки кеше үз-үзенә, үз теләкләренә яраклашырга тырыша, күпчелек очракта нәрсә уйлый, шуны эшли, шул рәвешле, Аллаһ каршында гөнаһлы була. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә үз хәдисендә: «Синең иң явыз дошманың – синең үзеңдә булган нәфесең», – дип әйткән. Әгәр кеше үз теләкләренә ирек биреп, каршылык кылмаса, ул үзе үк җанының һәлак булуына ярдәмче була.

Бу хакыйкатьне Аллаһы Тәгаләгә якын булган, Аның яраткан коллары – әүлияләр күптән аңлаганнар. Алар кешеләргә дә моны аңлатырга тырышып, нәфесләренә каршы торырга өндәгәннәр. Барлык төр явызлыкның, начарлыкның башлангычы үз нәфесенә каршы тора алмаудан икәнлеген таныган кеше җанның зәгыйфьлеге һәм бу дөньяда аның көннәре санаулы булуы турында уйланган.

Аллаһы Тәгалә кешеләрне шулай итеп яраткан ки, алар үзгәреш тә кичерәләр. Үз өстендә нык эшләү нәтиҗәсендә кешенең нәфесе рухи яктан үсә, яхшы якка үзгәрә. Кеше нәфесенең дәрәҗәсе Аллаһы Тәгаләгә якын яисә Аннан ерак булуы белән билгеләнә.

Тәсаувыфта нәфеснең 7 баскычы билгеле. Хак юлдан баручы кеше нәфесенең камиллеккә ирешү юлында бер-бер артлы шушы баскычларны үтә һәм ахыргысына килеп җитә.

## Нәфси-әммәра

Гарәп теленнән тәрҗемә иткәндә «боерык бирә торган нәфес» дигән мәгънәдә килә. Нәфси әммәра – явызлыкның, әхлаксызлыкның чыганагы. Кашани фикере буенча, бу төр нәфес тәнне материаль дөньяга китерә, кешедә рәхәтлек һәм теләк көчен кабыза, җанны түбәнлеккә төшүгә этәрә. Бу баскычта нәфес үз хуҗасын барлык теләкләрен канәгатьләндерергә чакыра. Шуңа да кеше бернәрсәгә дә карамыйча үз теләкләренә буйсына, шәһвәтен канәгатьләндерә. Коръәндәге «Йосыф» сүрәсенең 53 аятенә дә бу төр нәфескә ишарә ясала:

**«Әмма шулай булса нәфесемне дөресләмим, чөнки нәфес явызлыкка өндидер, мәгәр Раббымның рәхмәте ирешкән кешеләр генә нәфес өндәгән явыз эшләрдән котылыр. Әлбәттә, минем Раббым ярлыкаучы вә рәхмәтле».**

«Йосыф», 12:53

## Нәфси-ләввәмә

Гарәп теленннән тәрҗемә иткәндә «гаеп итә торган нәфес» дигән мәгънәне аңлата. Тәсаувыфта җанның бер өлеше белән яктыртылган һәм шушы нур хисабына уяулыгын саклаган нәфесне шулай атыйлар. Бу баскычта нәфес үзенең кылган гамәлләрен аңлый. Шуңа да үзен гаепли һәм башка ул гамәлләрен кылмаска тырыша. Ләкин камилләшмәгәнгә күрә, бу гөнаһларын яңадан кыла. Шулай да нәфси-ләввәмәдә берникадәр уңай үзгәрешләр дә күзәтелә.

## Нәфси-мүлхәмә

Гарәп теленнән тәрҗемә иткәндә «күтәренкелеккә ирешкән нәфес» дигән мәгънәне аңлата. Яхшылыкны яманлыктан аера алган ихтыяр «нәфси-мүлхәмә» дип атала. Нәфеснең камиллеккә ирешү юлында бу өченче баскычы. Аллаһ ярдәме белән бу нәфес үз савапларын һәм гөнаһларын аңлый, шуңа да, Аллаһтан кала бар нәрсәдән дә читләшә. Бу нәфес ярату халәтендә, ул фәннәрне ярата, тыйнак, авырлыкларга да әзер. Ул кешеләрдән читләшеп, Аллаһка якыная, матур һәм акыллы сүзләр әйтә.

## Нәфси-мутмәиннә

Гарәп телендә «тынычлыкка ирешкән нәфес» дигән мәгънәне аңлата. Ул нәфеснең дүртенче баскычы. Бу нәфес начар сыйфатлардан ерак, югары әхлаклылыгы белән аерылып тора. Кашани фикере буенча, мутмәиннә – җанның нуры белән яктыртылган, начар сыйфатлардан ераклашкан нәфес. Бу нәфес илаһилыкка юнәлгән. «Фәҗер» сүрәсенең соңгы аятьләрендәге «Җәннәткә кер!» дигән сүзләр шушы төр нәфескә карый. Бу баскычта «Йә, нәфси-мутмәиннә!» сүзләре белән нәфеснең канәгатьсезлеге тәгәлләнә. Мондый төр нәфесле кешенең җаны хак инану белән тулы. Ул шәригатьнең кайбер серләрен аңлаган, күркәм сыйфатларга (шәфкатьлелек, дөреслек, кече күңеллелек) ия. Һәрдаим өметләнә, буйсына, сабырлык кыла һәм шөкер итә. Аның җаны һәрвакыт Аллаһы Тәгаләне мактый, башкаларның кимчелекләрен яшерә һәм хаталарын гафу итә. Ул Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әхлагыннан үрнәк алып яши һәм моннан бик нык канәгатьлек ала. Аллаһы Тәгаләнең ярдәме белән үзенә берникадәр яңалыклар ача.

## Нәфси-разыйййә

Гарәп телендә «канәгатьлелеккә ирешкән нәфес» дигәнне аңлата. Камиллеккә ирешү юлында бу нәфеснең бишенче баскычы. Бу баскычта нәфес үз ихтыярыннан баш тартып, бары тик Аллаһы Тәгаләнең кушканнарына буйсына. Бернәрсәгә дә зарланмый. Күрсәтмәләрне үти, тыйганнардан тыела, югары әхлаклылыкка ия.

## Нәфси-мәрзиййә

Гарәп телендә «башкалар канәгать булган нәфес» дигәнне аңлата. Бу нәфеснең алтынчы баскычы. Аллаһы Тәгалә дә бу нәфестән канәгать. Нәфеснең әлеге баскычына ирешкән кеше дөньяви теләкләреннән читләшә. Аңа башкаларның хаталарын кичерә белү, дөрес фикерләү, рәхимлелек, кешеләргә карата ярату, юмартлык кебек сыйфатлар хас. Болар барысы да Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы хакына. Бу нәфескә кайбер яшерен серләр дә билгеле була. Мондый төр нәфесле кеше Аллаһы Тәгалә әйткәнне генә ишетәчәк, ул кушканны гына кылачак һәм ул рөхсәт иткәнне генә әйтәчәк. Аллаһның ярдәме һәм кодрәте белән нәфси-мирзиййә башка кешеләргә дә тәэсир итә ала.

## Нәфси-кәмилә

Гарәп телендә «камиллеккә ирешкән нәфес» дигән мәгънәне аңлата. Тәсаувыфта камиллекнең югарылыгына ирешкән, барлык күркәм сыйфатларга ия булган нәфесне шушы исем белән атыйлар. Шулай ук аны нәфси-гудсиййә, нәфси-сафиййә, нәфси-зәкиййә дип атау да бар. Бу нәфеснең камиллеккә ирешүенең җиденче баскычы.

■ ***Сәхифәне Лилия Җиһан әзерләде***

# Спорт һәм Ислам дине

**Актив рәвештә спорт белән шөгыльләнү исламга каршы киләме? Моның уңай һәм тискәре яклары нәрсәдә чагыла? Бүгенге мөселман спортчыларына нинди таләпләр куела? Бу һәм башка сорауларга ТР Джиу-Джитсу Федерациясе президенты Айрат Калимуллин җавап бирде.**



*– Актив рәвештә спорт белән шөгыльләнү һәм шул ук вакытта диндә булу бер-берсенә каршы килә диган караш яшәп килә. Бу чыннан да шулаймы?*

– Спорт белән мавыгучы һәрбер мөселман гыйбадәт кылырга да, шулай ук яраткан спорт төре белән дә шөгыльләнергә вакыт таба. Кайбер кешедә мөселманнар спорт белән шөгыльләнми диган уй чыннан да туа ала. Әмма үземнең практикадан чыгып шуны әйтеп була: алар спорт белән шөгыльләнә, ә кайберләре хәтта бик актив һәм җитди итеп тә. Мөселманнар да бит гади кешеләр: алар дәүләтебезнең гражданнары булып торалар, алар да шулай ук матур итеп киенергә, матур машиналарда йөрергә, матур спорт төре белән шөгыльләнергә яраталар. Шуңа күрә монда берниндидә үзенчәлекле әйбер юк, дип уйлыйм.

*– Ислам тарихында спорт өлкәсендә зур уңышларга ирешкән дини хезмәткәрләр турында ни әйтә аласыз?*

– Безнең пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәләмне генә алсак та, ул – бик көчле кеше булган. Аллаһы Тәгалә аңа шундый нигъмәт бирә. Кайбер чыганакларда Пәйгамбәребездә берничә кеше көче бар иде, дип әйтелә. Шулай ук Пәйгамбәребез галәйһис-сәләмнең тормышыннан бер мисал китереп була. Беркөнне аның янына бер кеше килеп, үзе белән көрәшергә тәкъдим итә. Бу кеше Рукана исемле көрәшче була. Һәм аның бер генә кешегә дә җиңелгәне булмаган. Пәйгамбәребез аннан җиңгән кешегә ни булачагын сорагач, ул үзенең бер сарыгына төртеп күрсәтә. Пәйгамбәребез, әлбәттә, бик җиңел генә бу кешене җиңә һәм сарыкны ала. Әмма бу Руканага ошамый һәм ул кабат бер тапкыр көрәшергә тәкъдим итә. Пәйгамбәребез кабат ризалаша һәм җиңүчегә ни булачагын сорый. Рукана үзенең бер сарыгына күрсәтә. Бу көрәштә дә Мөхәммәд галәйһис-сәләм бик җиңел генә җиңү яулый. Шулай дүрт тапкыр кабатлана. Рукана бу көрәштән соң Пәйгамбәребезгә: «Ий, Мөхәммәд, Аллаһ белән ант итәм, мине моңарчы беркемнең дә җиңгәне юк иде әле», – дип әйтә. Шушы сүзләреннән соң ул ислам динен кабул итә, ә Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм аңа сарыкларын кире кайтара һәм: «Ислам динен кабул итеп, дөрес эшләдең», – дип әйтә.

Безнең кайбер республика башлыкларыбызга карасак, алар да спорт белән бик актив шөгыльләнәләр. Үзебезнең Республика башлыгыбыз автоспорт белән шөгыльләнеп, күп кенә дәрәҗәләргә ирешкән кеше. Дөньяда да спорт белән шөгыльләнеп, дан казанган мөселманнар аз түгелдер, дип саныйм.

*– Спортның кайсы төрләре мөселманнар өчен кулайрак дип санала?*

– Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм безнең өчен рөхсәт итеп калдырган кайбер спорт төрләрен бар. Ул йөгерүне, атта чабуны, уктан атуны, көрәш кебек спорт төрләре рөхсәт иткән. Һәм, әлбәттә, кешеләргә зыян китерә торган спорт төрләреннән ерак торырга кушкан. Биткә кул һәм аяк белән суга торган спорт белән шөгыльләнмәскә киңәш иткән. Әмма бүгенге көндә, әлбәттә, андый спорт төрләре бар, алар белән шөгыльләнәләр. Ни өчен соң биткә сугарга ярамый? Бит – ул тәндә иң югарыда урнашкан орган, шул орган белән без Аллаһ каршына басып, гыйбадәт кылабыз, бер-берләребез белән дә йөзләргә карап аралашабыз. Һәм әгәр дә кешенең йөзе бозылган хәлдә йөрсә, аңа калганнар тарафыннан тискәре карашлар да булырга мөмкин, шулай ук гыйбадәттә дә бу матур күренеш булмас иде. Шулай ук башта без фикерли, уйлый торган ми дә урнашкан. Аны да саклау мөһим мәсьәлә.

*– Ислам күзлегеннән караганда, нинди спорт төрләре белән шөгыльләнмәсәң яхшырак?*

– Әлбәттә, иң беренче чиратта, йөзгә зыян сала торган, кешенең акылына, баш миенә зыян сала торган спорт төрләре ислам динендә хупланылмый. Һәм инде бигрәк тә кешенең үлеменә китерә торган төрләр дә бар. Боларның барысыннан да ерак торырга киңәш ителә. Мәсәлән, Америкада берничә ел рәттән рингта кешеләрнең бик тирән җәрәһәтләнүе турында ишеткәнем бар. Мондый куркыныч спорт төрлрендә зур гонорарлар түләнелә. Шуңа күрә спортка яңа килгән кешенең тизрәк байыйсы килеп, акча эшләргә омтыла. Әмма аларга каршы тәҗрибәлерәк спортчы куелса, әлбәттә, моның нәтиҗәсе булып кешедә зур җәрәһәтләр салына.

*– Кайбер дини кешеләр спорт ярышларын тыелган, дип әйтәләр. Аларда катнашмаска, аларны карамаска өндиләр. Андый кешеләргә ни дип җавап биреп була?*

Әйе, бу мәсьәләдә артык гыйлеме булмаган кешеләр дә бар. Һәрбер гамәлдә дә аның асылына карап, шул эшне бик игътибар белән өйрәнергә кирәк бит. Югарыда сөйләп узганча, Пәйгамбәребез заманында ук мондый төр эшләр тыелмаганлыгы ачыклана. Анда җиңгән кешегә сарык вәгъдә ителде. Шуңа күрә мөселманнар арасында да җиңүчегә берәр төрле бүләк куелса, бу тискәре күренеш булып саналмый. Димәк, бу мөселман җиңгән кешегә бүләк бирергә генә тели дигәнне аңлата һәм бу уңай күренеш.

Азартлы уеннар – болары икенче мәсьәлә. Уен өчен акча кую (ставка) шулай ук хуплана торган гамәлләрдән түгел. Ә мөселман кешесенең нинди дә булса спорт төре белән шөгыльләнүеннән берниндидә зыян күрмим мин. Киресенчә, безнең тәнебез безнең өчен Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән әманәт булып тора. Безгә бу тән вакытлыча гына кулланып торырга бирелгән. Һәм без бу четрекле мәсьәләгә бик җитди карарга тиешбез: үзебез турында, тәнебезнең яхшы физик халәттә булуын кайгыртырга, сәламәтлегебезне сакларга, төрле тренировкалар ясарга тиешбез. Бу чыннан да бик мөһим, чөнки һәр кеше Кыямәт көнендә үзенең тәне турында соралачак.

***– Бүгенге көндә үзләренең дини кешеләр икәнлеге басым ясый торган мөселман спортчылары барлыкка килде. Алар уен алдыннан дога кылалар, яки уен барышында сәҗдә кылып алалар. Ислам этикасы тарафыннан бу рөхсәт ителәме?***

– Моңа кирәгеннән артык игътибар бирүчеләр бар. Кеше җиңгәннән соң ни эшләсен инде? Әлбәттә, шатлана, һәм ул Аллаһка шөкер әйтә. Ә кем аңа бу җиңүне бирә? Әлбәттә, Аллаһы Тәгалә. Зур спорт ярышларында җанатарлар флаглар белән килеп, шуларны күтәреп утыралар, аларга бит беркем дә игътибар итми. Монда да шулай ук. Һәм бу, киресенчә, кирәк әйбер дә булып тора: спортчының бу гамәлләреннән дин белән танышалар, диннең дөньядан аермаганлыгын, аның да тыныч һәм имин дин икәнен беләләр. Бу дингә уңай караш тудыруга да ярдәм итә.

*– Мөселман-спортчы ничек киенергә тиеш. Шәригатьтә моңа нинди кагыйдәләр каралган?*

– Мөселман кеше, иң беренче чиратта, пөхтә, җыйнак киенергә тиеш. Моның турында Пәйгамбәребез Мөхәммәд тә бик күп тапкырлар әйтеп уза. Ул: «Чисталык – иманның яртысы», – дип әйткән. Бу эчке һәм тышкы чисталык та. Әмма кеше белән аралашканда, игътибарыбызны иң башта кешенең тышкы кыяфәтенә юнәлтәбез: киеме чистамы, үзе пөхтәме,тышкы кыяфәте матурмы? Әгәр дә кешегә карагач, бу матурлыкны күрмәсәк, әлбәттә, ул үзеннән читләштерәчәк кенә. Шуңа күрә үз-үзеңә игътибарлы булырга кирәк. Шулай ук янәшәңдә булган мөселманнарга да игътибарлы булу кирәк, әгәр аңарда берәр төрле кимчелек күрсәк, аңа аның турында йомшак кына әйтергә кирәк. Шул ук вакытта аның дәрәҗәсе турында онытмау мөһим, чөнки, әйткәнемчә, үзебезнең һәрбер сүзебез өчен без җавап тотачакбыз.

*– Җиңү өчен акча алу – Ислам бу мәсьәләгә ничек карый?*

– Бүгенге көндә футбол, баскетбол, хоккей кебек спорт төрләре дөнья-күләм ярышларга әйләнделәр. Аларда да, Олимпия уеннарында да һәр спортчы үзенең илен яклап, чыгыш ясый. Ә моның өчен бик күп көч кирәк. Кеше бар йөрәген биреп, шушы эшкә алына, ә бу бик җиңелләрдән түгел. Ә инде шушы хезмәтнең нәтиҗәсе буларак, дәүләт акча бирсә, бу уңай күренеш. Әгәр кешенең бөтен эшли торган эше булмаса, спорт белән профессиональ шөгыльләнүе үзе эш булып бара.

*– Әңгәмә өчен зур рәхмәт сезгә!*

**«Хозур ТВ»**

# Мөхәррам ае

Мөхәррам аеның 10 нчы көне – «Гашурә» көне. Үз вакытында Гомәр Әл-Хаттаб разыйаллаһу ганһү нәкъ менә мөхәррам аен һиҗри календарьнең беренче ае итеп билгеләде. Мөселманнар яңа елны бәйрәм кебек билгеләп үтмәсәләр дә (Пәйгамбәребез ике бәйрәм – Ураза һәм Корбан гаете белән килде), аны яңа фазага аяк басу кебек кабул итәләр. Яңа елда бер елга үтәләсе яңа планнар корыла, яңа өметләр баглана һ. б.

Мөхәррам ае зөлхиҗҗә аеннан соң килгәнгә күрә дә, Гомәр Әл-Хаттаб бу айны беренче ай итеп куйгандыр. Моның да үз сәбәбе бар:

«Кем дә кем начар сүзләр сөйләшмичә, бозыклыклар кылмыйча бу Йортка (Кәгъбәгә) хаҗ кылса, ул өенә анадан туган сабый кебек (пакь, гөнаһларсыз) кайтыр» (хәдис).

Хаҗ кылганнан соң кеше үзенең гөнаһларының авырлыгыннан котылып кайтыр, шуңа күрә аны сабый бала белән чагыштырып булыр иде. Һәм әле генә хаҗ кылып, гөнаһларыннан арынып кайткан кеше, яңа елга чиста килеш аяк баса. Бу халәт кешегә алдагы елга оптимизм һәм уңай караш белән карарга мөмкинлек бирә, шулай ук элеккеге хаталарга һәм гөнаһларга әйләнеп кайтмыйча, елны тулысы белән шушы рухи чисталыкта үткәрергә этәргеч була.

Әмма мөхәррам аеның беренче ай булуы гына аны шундый зур дәрәҗәләргә күтәрми. Беренчедән, бу айда олы кичә – «Гашурә» көне бар, икенчедән, бу ай һәр көнендә ураза тоту бик фазыйләтле булуы белән аерылып тора. Мөхәммәд Мостафа галәйһис-сәләм:

«Рамазан аеннан соң иң фазыйләтле ураза – Аллаһ аенда, мөхәррамда», – дип әйткән.

Мөхәррам аеның һәрбер көне фазыйләтле, шуңа күрә мөселман кешегә мөхәррам ае буе, яки калган айларга караганда бу айда күбрәк көннәр ураза тоту рөхсәт ителә. Гашурә көне бу көннәр арасында аерым урынны билəп, Аллаһы Тәгаләдән зур саваплар бирелә торган көн буларак аерылып торса да, ул әле Ислам дөньясындагы кайбер тарихи вакыйгаларга да бәйле.

Мөхәммәд Мостафа галәйһис-сәләмгә пәйгамбәрлек кешеләр мәҗүсилек динендә булганда, потларга табынган вакытта иңә. Әмма пәйгамбәрләр алып килгән барлык кануннар да юкка чыкмаган була: гарәпләр телдән телгә, нәселдән нәселгә Ибраһим, Исмәгыйль галәйһимус-сәләм пәйгамбәрләрнең законнарын тапшырган, яһүдиләр һәм насаралларда Муса һәм Гайсә галәйһимус-сәләм пәйгамбәрләргә иңгән китаплар (үзләре үк тарафыннан үзгәртелгән булса да) бар иде. Кызганычка, ул гореф-гадәтләрдә, ул китапларда һәм законнардагы күп кенә әйберләр үзгәртелгән, зур хаталар ясалган, шуңа күрә кайда шайтан вәсвәсәсе аша бозылган текст, ә кайда Аллаһы Тәгалә әмере икәнлеген әйтү кыен иде.

Мөхәммәд пәйгамбәр исә аларның берсенә дә таянмады, чөнки аңа турыдан-туры Аллаһы Тәгаләдән вәхи иңдерелде. Ул кешеләргә аларның хаталарын һәм алдашуларын күрсәтте, шулай ук яхшылыкка һәм файдалы гамәлләргә өйрәтте.

Мөшрикләрнең Аллаһы Тәгалә шәригатенә туры килмәгән күп кенә гамәлләре кире кагылды, ә берәр пәйгамбәрдән үзгәрешсез килгән гамәлләр шул килеш калдырылды. Әгәр дә берәр гамәл үзгәреш кичергән булса, ул беренчел халәтенә китерелде. Исламда калдырылган гамәлләргә хаҗ, гомрә (ел әйләнәсендәге кече хаҗ), хаҗ вакытындагы тәлбия (мөшрикләр аны үзгәрткән булалар, әмма Пәйгамбәребез аны шәригатькә муафыйк итеп үзгәртте), Гашурә көнне ураза тоту һ. б. керә.

Гашурә уразасы турында Гарәбстанда яшәүчеләргә бик күптәннән билгеле була. Гарәпләр ул көнне ураза тотканнар һәм Кәгъбәтуллаһның тукымасын алыштырганнар. Гайшә разыйаллаһу ганһә: «Рамазан (аенда ураза тоту) мәҗбүри булганчы, алар Гашурә көнендә ураза тоттылар һәм бу көн Кәгъбәне каплый торган көн иде», – дип әйткән.

Гайшә разыйаллаһу ганһәдән шулай ук: «Җаһилият чорында корәешләр Гашурә көнендә ураза тоттылар, Рамазан ае уразасы мәҗбүр булганчыга кадәр Пәйгамбәребез бу көндә ураза тотарга кушты. (Рамазан уразасы мәҗбүр булгач), Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм: «Кем тели, шул тотсын, ә кем тели – калдырсын», – дип әйтте», – дигән хәдис тапшырыла.

Яһүдиләр дә бу көнне зур бәйрәмгә санаганнар. Әбү Муса Әл-Әшгаридан тапшырыла: Хәйбәр кешеләре (яһүдиләр) Гашурә көнендә ураза тоттылар, ул көнне бәйрәмгә санап, хатын-кызларын кыйммәтле киемнәргә киендерделәр, бизәндерделәр. Шуннан соң Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәләм (мөселманнарга): «Сез дә бу көнне ураза тотыгыз», – дип әйтте.

Кайбер хәдисләрдә насараларның да бу көндә ураза тотулары турында сөйләнелә. Шуңа күрә пәйгамбәрләрнең законнары, гореф-гадәтләре гасырлар аша узып, халык арасында сакланып калган, дип әйтергә була.

Рамазан аенда ураза тоту мөселманнарга беренче чорда ук фарыз булмады. Ул фарыз булганчы әле ике баскыч үтте. Мөгаз бине Җәбәл дигән сәхабә: «Намаз өч чор үтте, ураза да өч чор үтте. Башта (Пәйгамбәребез) һәр айның 3 көнендә һәм Гашурә көнендә ураза тота иде, аннан соң Аллаһы Тәгалә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ
عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ ﴿١٨٣﴾ أَيَّامًا
مَّعْدُودَاتٍ ۚ فَمَن كَانَ مِنكُم مَّرِيضًا أَوْ عَلَىٰ سَفَرٍ
فَعِدَّةٌ مِّنْ أَيَّامٍ أُخَرَ ۚ وَعَلَى الَّذِينَ يُطِيقُونَهُ فِدْيَةٌ
طَعَامُ مِسْكِينٍ ۖ فَمَن تَطَوَّعَ خَيْرًا فَهُوَ خَيْرٌ لَّهُ ۚ
وَأَن تَصُومُوا خَيْرٌ لَّكُمْ ۖ إِن كُنتُمْ تَعْلَمُونَ ﴿١٨٤﴾

**«Ий мөэминнәр! Сездән әүвәлгеләргә ураза тоту фарыз ителгәне кебек, сезгә дә һәр елны бер ай ураза тоту фарыз ителде, шаять, аны калдырудан яки аңа кимчелек китерүдән сакланырсыз! Ураза саналмыш көннәр. Сезләрдән берәрегез авырса, яки сәфәрдә булса, уразаны тотмасын. Авыру кеше сәламәтләнгәч, сәфәрдәге кеше өенә кайткач, калган көннәрен бер көн өчен бер көн тотып тәмам итәр. Авырлык белән тотучыларга фидия лязем – бер көн өчен бер мескенне бер көн ашату. Берәү бер мескен урынына күбрәк мескенне ашатса, артыгы үзенә хәерле. Әммә мескеннәрне ашатып өстегездән төшерүгә караганда, ураза тотуыгыз сезнең өчен хәерле, әгәр белсәгез».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183-184

дигән аятьләрне иңдергәч, кайбер кешеләр ураза тотты, кем тели исә бер көн ураза өчен бер фәкыйрь кешене ашатты һәм бу алар өчен ураза кебек язылды. Бу бер ел буена сузылды, аннан соң Аллаһы Тәгалә:

شَهْرُ رَمَضَانَ الَّذِي أُنزِلَ فِيهِ الْقُرْآنُ هُدًى لِّلنَّاسِ
وَبَيِّنَاتٍ مِّنَ الْهُدَىٰ وَالْفُرْقَانِ ۚ فَمَن شَهِدَ مِنكُمُ
الشَّهْرَ فَلْيَصُمْهُ ۖ وَمَن كَانَ مَرِيضًا أَوْ عَلَىٰ سَفَرٍ
فَعِدَّةٌ مِّنْ أَيَّامٍ أُخَرَ ۗ يُرِيدُ اللَّهُ بِكُمُ الْيُسْرَ وَلَا يُرِيدُ
بِكُمُ الْعُسْرَ وَلِتُكْمِلُوا الْعِدَّةَ وَلِتُكَبِّرُوا اللَّهَ عَلَىٰ مَا
هَدَاكُمْ وَلَعَلَّكُمْ تَشْكُرُونَ ﴿١٨٥﴾

**«Рамазан ае бик шәрифле ай, ул айда Аллаһтан кешеләргә туры юлны күрсәтүче һәм һидаятьне ачык бәян кыла торган Коръән иңдерелде. Сезләрдән Рамазан аена ирешкән һәрберегез, әлбәттә, ураза тотсын! Рамазан аенда берәү авыру булса яки мәшәкатьле озын сәфәрдә булса, ураза тотмасын, авыру кеше сәламәтләнсә, мосафир өенә кайткач, калдырылган көннәр санынча башка вакытта каза кылырлар».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:185

дигән аятьне иңдерде. Шушы вакыттан бирле Рамазан аена ирешкән кешеләр өчен ураза фарыз булды. Сәфәрдә булган кешеләр кайткач, каза кылырга, ә ураза тота алмаучы олы кешеләр фәкыйрь кешеләрне ашатырга тиеш булдылар», – дип әйткән.

Кыскача бу чорларны түбәндәгечә аңлатып булыр иде:

1. Иң башта нәфел уразасы буларак ураза Гашурә көнендә һәм һәр айның 3 көнендә тотылган. (Бу Мәккә шәһәрендә башланып (һиҗрәткә кадәр), Мәдинәгә күчү белән тәмамлана).

2. Шуннан соң бу ураза фарызга әйләнде, әмма ураза тотучы ураза белән фәкыйрьләрне ашату арасында сайлый алган. Шулай итеп, мөселман ел дәвамында 37 көн ураза тотарга яки шуның кадәр кеше ашатырга тиеш булган. (Бу чор Мәдинәгә күчкәч, бер ел дәвам итә).

3. Шуннан соң Аллаһы Тәгалә әмер рәвешендә Коръәндә уразаны Рамазан ае буена тотарга куша. Һәм Рамазан аенда фәкыйрьләрне ашату һәм ураза арасында сайлау мөмкинчелеге булмый, әмма олы кешеләргә, авыру һәм юлда булучыларга карата хөкем шул ук кала.

Менә шушы этаплардан соң Гашурә һәм 3 көнлек ураза нәфел булып калдылар.

**Гашурә уразасының фазыйләтләре:**

1. Ислам диненең беренче елларында Гашурә

# һәм Гашурә көне



уразасы фарыз ураза булып, соңыннан нәфелгә генә калса да, ул үзенең олуг дәрәҗәсен югалтмады. Әр-Рубайа бинт Мөгаза разыйаллаһу ганһә:

«Пәйгамбәр галәйһис-сәләм Гашурә көненең уртасында әнсарлар янына бер кешене җибәреп, аларга: «Кем иртәдән уразага кермәде, көннең калган өлешен уразада үткәрегез, ә кем иртәдән уразада, шул кеше уразасын дәвам итсен», – дип әйтергә кушкан. Шуннан соң без үзебез дә уразага кердек, балаларыбызга да уразага керергә куштык. Без аларга буялган йоннан уенчыклар ясый идек. Әгәр берәрсенең карыны ачып, елый башласа, без аларга ифтарга кадәр шушы уенчыкларны бирә идек», – дип әйткән.

2. Гашурә көнендә күп гасырлар элек бер зур вакыйга – Аллаһы Тәгаләнең могҗизасы була: Муса галәйһис-сәләм үзенең халкы белән артыннан куып барган гаскәрдән кача. Ул гаскәрнең башлыгы Фиргавен була. Аллаһы Тәгалә Муса халкына диңгездә юл яра, диңгез суы икегә бүленеп, коридор барлыкка килә, ә диңгез төбендәге җир коры була. Бу могҗизаны күрсә дә, үзенең имансызлыгы белән сукырайган Фиргавен барыбер шушы коридорга керә. Муса үз халкы белән икенче ярга җитүгә, Аллаһы Тәгалә диңгезне кире куша һәм Фиргавен үз гаскәре белән су астында кала. Бу баладән котылу хөрмәтенә Муса шул көнне ураза тота башлый, аның халкы да аңа иярә. Ибн Габбас разыйаллаһу ганһү мондый хәдис тапшыра:

«Пәйгамбәребез Мәдинә шәһәренә һиҗрәт кылганнан соң, шушы шәһәрдә яшәгән яһүдиләрнең Гашурәдә ураза тотканнарын күрде. Ул алардан: «Нәрсә бу?» – дип сорады. Яһүдиләр: «Бу көнне Аллаһы Тәгалә пәйгамбәребез Мусаны Фиргавеннән һәм аның гаскәреннән коткарган. Муса да бу көнне ураза тоткан», – дип җавап кайтардылар. Пәйгамбәребез аларга: «Муса пәйгамбәргә карата минем хокукым беренчедер...(мин лаеклырак)», – дип җавап бирде һәм үзе дә уразага кереп, калганнарга да бу уразаны тотарга кушты», – дип әйткән.

3. Әгәр дә кеше бу уразаны хак курку белән курып, ярлыкауга өмет белән башкарып чыга алса, аның узган ел өчен булган гөнаһлары ярлыканачак. Пәйгамбәребез галәйһис-сәләмнән Гашурә уразасы турында сорагач, ул: «Ул узган елгы гөнаһларның кичерелүенә сәбәп була», – дип әйткән.

Гашурә көне – мөхәррам аеның 10 нчы көне, бу сүз «гашәрә» тамырыннан, ягъни «ун» сүзеннән ясалган. Аллаһ илчесе уразаны Гашурә көнгә бер көн өстәп, йә 9 һәм 10, йә 10 һәм 11 тотарга кушты. Бу калган дин әһелләреннән аерылып тору өчен шулай кертелгән. Ибне Габбас разыйаллаһу ганһүдән тапшырылган хәдистә:

«Әгәр мин икенче елга кадәр яшәсәм, тугызы көнне, һичшиксез, ураза тотачакмын», – дип әйтелә. Шулай ук Ибне Габбас болай дип әйткән: «Аллаһ илчесе Гашурә көнне ураза тотканда, калганнарга да тотарга кушты. Әмма алар: «Йә, Аллаһ илчесе, бу көнне яһүдиләр һәм насаралар да олуглыйлар», – дип әйттеләр. Шуннан соң Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәләм:

«Киләсе ел җиткәч, ин шә Аллаһ, тугызынчы көнне дә ураза тотачакбыз», – дип әйте», – диелә.

Имам Әхмәд хәдисләр җыентыгында мондый хәдис китерелә: «Гашурә көнендә ураза тотыгыз. Бу эшегездә яһүдиләргә каршы булып, йә бер көн алдан, йә бер көн арттан уразага өстәгез».

Бу уразадан нинди файда алып була? Бу дата нинди вакыйгаларга бәйле?

1. Гашурә көнендә ураза тоту – Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәләмнең сөннәте, шуңа күрә бу көндә ураза тоту хәерле гамәл санала. Кеше Пәйгамбәрнең үрнәгенә күбрәк ияргән саен, ул кешене Аллаһы Тәгалә дә шулкадәр күбрәк ярата. Шулай ук, һәрбер яхшы гамәл үзе артыннан икенче яхшы гамәлне ияртә. Ә һәрбер начар гамәл үзе артыннан икенче начар гамәлне ияртә.

2. Бу көннең уразасын Пәйгамбәр Мөхәммәд һәм аның сәхабәләре генә тотып калмыйча, шулай ук Муса һәм аның сәхабәләре дә тоткан. Бу урында шуңа басым ясарга кирәк: Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм бу көндә ураза тотуны яһүдиләрдән алмаган. Алда әйтеп үтелгәнчә, ул бу уразаны Мәдинәгә күченгәнче үк тоткан. Ә Мәдинәгә күченгәч, ул яһүдиләрдән ни өчен алар да бу көнне уразада булуларын һәм бу көнгә нинди мәгънә биргәннәрен беләсе килеп кенә сорый. Шуңа күрә Пәйгамбәребез бу уразага тагын бер көн өсти. Бу, киресенчә, Пәйгамбәребезнең аларга охшарга тырышмаганлыгын күрсәтә.

3. Гашурә көне безгә Аллаһы Тәгаләнең рәхимлелеге турында, Аның пәйгамбәрләренә карата яратуын исебезгә төшерә. Пәйгамбәләрнең үз халкы аларны онытсалар да, зурламасалар да, Аллаһ бу вазифаны икенче халыкка бүләк итә. Шуңа да мөселманнар бу вакыйгалар турында онытмаска тиеш.

4. Бу көн безгә кешеләр арасындагы якынлык туганлык җепләре белән генә үлчәнмәгәнлеген күрсәтә. Чын туганлык дип диндәге кардәшлекне атап булыр иде. Пәйгамбәр галәйһис-сәләм яһүдиләргә үзен Мусага аларга караганда да якынрак дип әйткән. Гәрчә алар Муса яки аның сәхабәләре нәселеннән булсалар да. Алар Муса алып килгән тәгълиматтан күптәннән читләштеләр, ә мөселманнар әле дә Мусаны пәйгамбәр буларак яраталар.

5. Гашурә көне Аллаһы Тәгаләнең кодрәтен дә күрсәтә торган көн. Аллаһы Тәгалә бу көндә зур могҗиза – диңгезне икегә аерып күрсәтте. Бу исә Аллаһы Тәгалә өчен бернинди мөмкин булмаган әйберләр юк икәнен күрсәтә. Барлык физика законнары, без белгән һәм белмәгән фәннәрне Аллаһы Тәгалә Үзе бар кылды һәм Үзе теләгәнчә алар белән идарә итә ала. Әмма бу законнар Аллаһның Үзенә берничек тә тәэсир ясый алмыйлар.

Шуңа күрә, тормышта ниндидер кайгы-хәсрәт килеп чыкса, бу Аллаһтан сынау булып, аннан чыгу юлын да Аллаһы Тәгалә Үзе бирәчәк дигәнне аңлата. Безгә үзебез өстендә эшләргә генә кала.

### Гашурә – бик күркәм көн

Гашура көнендә шактый күп әһәмиятле, тарихи, сөенечле вакыйгалар булган. Шуларның аеручә мөһим булганнары Аллаһның пәйгамбәрләре белән бәйледер. Бу көнне Бөек Раббыбыз бу дөньяны, Адәмне яраткан, нәкъ бу көнне Адәм тәүбәсе кабул ителгән; Нух көймәсе тауга килеп җитеп, андагы мөэминнәр туфаннан котылган; бу көнне Ибраһим пәйгамбәр туган һәм мәҗүсиләрнең учагыннан коткарылган, Гайсә һәм Идрис пәйгамбәрләр күккә ашкан; Муса пәйгамбәр һәм аңа ияргәннәр Фиргавеннең эзәрлекләвеннән котылганнар, Фиргавенне шул көнне диңгез сулары йоткан; Юныс балык карыныннан исән-имин чыгып котылган; Әюб пәйгамбәр авыр чирдән савыккан; озак елларга сузылган аерылышудан соң Ягъкуб улы Йосыф белән очрашкан; Йосыф зинданнан чыккан; Сөләйман пәйгамбәр патша булган.

Шулай итеп, догалар, теләкләр кабул ителгән һәм бик күп бәла-казалардан котылуга сәбәп булганы өчен, Гашура көне котлы вә шатлыклы бер көн булып исәпләнә.

**Камил хәзрәт Сәмигуллин,**
**Татарстан Республикасы мөфтие**

# Болгар җыены Ислам Академиясендә эшлекле очрашу белән башланды



«Изге Болгар җыены» быел Ислам академиясендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендәге эшлекле очрашу белән башланып китте. Кунакларны академия ректоры Рафыйк хәзрәт Мөхәммәтшин каршылады һәм килгән кунакларны академия бинасы белән таныштырды. Түгәрәк өстәл форматындагы очрашу республика башлыгыбыз Рөстәм Миңнехановның чыгышы белән ачылып китте.

Болгар музей-заповедингының мәгариф, фән һәм мәдәният сораулары буенча Берләшкән Милләтләр оешмасы-ЮНЕСКО исемлегенә керүен искәртеп һәм 8 ел эчендә башкарылган нәтиҗәле хезмәт турында Татарстанның Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев сөйләде. Болгар Ислам академиясе Татарстанда гына түгел, Россиядә ислам белеме бирә торган төп югары уку йортыбыз, -диде ул.

Дин әһелләре белән эшлекле киңәшмәдә сүз академиянең үсеше һәм халыкара хезмәттәшлек турында барды. Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның чыгышы түбәндәгедән гыйбарәт иде: Ислам дине һәрвакытта белем бирүгә зур игътибар биргән! Кәлам Шәрифтә болай диелә: «Аллаһы Тәгалә сезнең арагыздан иман китерүчеләрне һәм төрле дәрәҗәләрдә белем бирелгән кешеләрне күтәрә» («әл-Муҗадилә» сүрәсе, 11 нче аять). Әлеге аятькә аңлатмаларда имам Газали «Ихйа» китабының беренче томында Габдулла бине Габбас разыйаллаһуның сүзләрен китерә. «Аллаһы Тәгалә галимнәргә иман китерүчеләрдән өстенлекне җитмеш дәрәҗәгә күбрәк бирә һәм ике дәрәҗәнең арасы – илле ел җәяү бару арасы кадәр».

Россиядә һәм Бәйсез Дәүләтләр берлеге илләрендә иң зур мөселман белем бирү үзәкләренең берсе – Болгар ислам академиясе – ачылышы татар халкының соңгы 10-15 елдагы төп казанышларының берсе булып тора. Академия эшләп китүне, үзенең әһәмияте буенча, 2005 елда Кол Шәриф мәчете ачылу белән тиңләргә мөмкин. Әлеге ике дини корылма татарларда рухи мирасның һәм Идел-Урал төбәгендә мөселман мәгарифенең данлыклы традицияләрен торгызуның символы булып торалар.

Аллаһның рәхмәте белән 2017 елда Болгар ислам академиясе беренче укучылары өчен үз ишекләрен ачты: 68 кеше кабул ителде, шуларның 16сы докторантурада, 52се магистратурада белем ала. Агымдагы 2018 елда беренче курска 60 кеше алу ниятләнә (магистратура – 45, докторантура – 15).

Шунысы куанычлы: Болгар Ислам Академиясе уңышлы үсеш ала һәм Россия халыкара югары уку йортлары белән үзара хезмәттәшлек урнаштыра. 2017 елның декабрендә Санкт-Петербург дәүләт университеты белән үзара хезмәттәшлек турында килешү имзаланды. 2018 елның февралендә Россия Фәннәр Академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институты белән дә хезмәттәшлек турында шартнамәгә кул куелды. Ә 2018 елның апрель аенда Рус Православие Чиркәвенең югары белем бирә торган рухи белем бирү оешмасы белән килешү төзелде.

Халыкара партнер-университетлар арасында Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең Шарҗа университеты, Нидерландның Лейден университеты, Төркиянең 29 май университеты, Марокконың Карауин университеты белән тыгыз хезмәттәшлекне билгеләп үтәргә мөмкин.

Бүген безнең алда Болгар ислам Академиясендә югары ислам белемен бирү сыйфатын һәм дәрәҗәсен арттыру бурычы тора. Без Мәрҗани, Курсави һәм Утыз Имәни кебек татар галимнәре-дин белгечләрен әзерләүне дәвам итәргә тиешле.

Чыгышымны йомгаклап мин, мөхтәрәм Рөстәм Нургали улы Миңнехановка һәм Минтимер Шәрип улы Шәймиевка, Камил Шамил улы Исхаковка, Рәфыйк хәзрәт Мөхәммәтшинга һәм барлык профессор-укытучылар составына Болгар ислам Академиясе үсешендә күрсәткән ярдәмнәре өчен рәхмәтемне белдерәм. Аллаһы Тәгалә сезнең тырышлыкларыгызны кабул кылсын һәм савапларын арттырсын, – дип тәмамлады мөфти.

Эшлекле очрашу тәмамлану белән ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендәге делегация «Изге Болгар җыены»ның тантаналы ачылышына мәйданга күчте.

■ dum.rt

# Мөселман яшьләре форумы



**Мөселман яшьләре форумы быел җәйге форматта дүртенче, ә гомумән алганда, алтынчы тапкыр уздырылды. Кышкы форум безнең 4 көнә көн, ә җәйге форум 7 көн дәвам итә. Форумны елдагыча Болгар җирлегендә уздырабыз. Быел ачылышны Казанда үткәреп, туры Болгарга юл тоттык. Анда форум делегатларын квест уены көтә иде. Квест уены делегатларның үзләренең бүлмәләренә керә алуга корылган иде, ягъни бүлмәләр һәрберсе дә ябык һәм аларны ачар өчен, ниндидер биремнәр аша үтәргә кирәк булды.**

Башкаларыннан аерылмалы буларак, быелгы форум күбрәк уку-укытуга, гыйлем алуга юнәлдерелгән иде. Без яшьләребезнең белемле галимнәр, яшьләргә яшьләр телендә гыйлемне ирештерә белүче остазлар белән очрашырга теләгәннәрен аңладык. Катнашучылар Идел буе төбәкләренең һәрберсеннән, Росиянең 14 ләп регионыннан бар иделәр: Мәскәү, Башкортстан, Чиләбе, Самара, Әстерхан, Оренбург, Көньяк Сахалин, Калининград; чит илләрдән: Казахстан, Индонезия, Берләшкән Гарәп Әмирлек-ләреннән. Берләшкән Гарәп Әмирлек-ләреннән килгән егетләр бу форумга махсус, тәҗрибә уртаклашу максатыннан килгәннәр. Бездәге форумны карап, үзләрендә дә шундый ук форум оештырырга ниятлиләр. Тәҗрибә уртаклашу, үзең белгәнне кешегә күрсәтү, аларның нәрсә белән кызыксынганнарын белү безнең өчен дә бик мөһим. Ислам академиясендә шәех Бүлбүлнең лекцияләрен дә нәкъ менә шушы егетләребез тәрҗемә кылып тордылар. Ә үз кешеләрең катнашканда, калганнарга бу тагын да кызыклырак тоелды.

Быелгы форумның үзенчәлеге – егетләр һәм кызлар дәресләрдән кала чараларда: мастер-класслар, физик күнегүләр, уеннар, олимпиада – боларның барысында да алар аерым булды.

Көн тәртибенә килгәндә, иртәнге якта яшьләребез физик күнегүләр ясадылар. Аннан иртәнге аш. Гомумән, көнгә 4 тапкыр ашау оештырылган иде. Дәресләр, яшьләрнең ял итү вакытлары, спорт уеннары, намаз укулар – болар барысы да бер-бер артлы үрелеп бара. Татарстан җирлегенә килгән яшьләребезгә без татар халкыбызның милли гореф-гадәтләрен, аулак өйләрне күрсәтергә теләдек. Оештыручы координаторларның ярдәме белән бу шактый күңелле килеп чыкты. Аларга аерым рәхмәт әйтәсебез килә! Алар хәтта коймак пешерә торган махсус җайланма алып килеп, коймаклар пешерделәр, йомыркалар кыздырып сыйладылар.

Быелгы мөгаллимнәребез – Әхмәт хәзрәт, Әбү Гали Әл-Әшгари. Алар яшьләребезне ике төркемгә: көчлерәк һәм башлангыч төркемнәргә бүлделәр. Көндез билгеле темага дәрес каралган булса, ахшамнан соң шушы ук остазларыбыз әңгәмә рәвешендә яшьләребезне борчыган сорауларга җавап бирделәр. Төшкә кадәр булган дәресләр хәдисләргә багышланган иде, Имам Нәвавинең «40 хәдис»ен анализладылар. Дәресләрнең икенче өлеше намаз турында иде. Бераз шикләнеп кенә бу темага алынсак та, дәресләр шактый файдалы булды. Монда намазның эчке дөньясы да, тышкы ягы да каралды.

Кунакларга килгәндә, быелгы форумда кунакка Зәкәрия хәзрәт Тимганов килде. Ул форумделегатларының үсешенә зур өлеш кертте, дип саныйбыз. Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин – форумыбызның даими кунагы. Ул вакытын һәм мөмкинлеген табып, ел да яшьләр белән очрашырга килә. Көне буе алар белән аралашып, әле спорт чараларында да катнашырга вакытын таба. Ел саен үткәрелгән сабантуйны (форумда сабантуй уеннары гына иде) быел олимпиада белән алыштырырга булдык. Без олимпиадада булган спорт төрләрен алып, үз кул астыбызда булган инвентарьләр белән бәйгеләр оештырдык. Әгәр ул керлинг икән, оештыручыларыбыз махсус пленканы җәеп, шунда сабынны су ярдәмендә шудырдылар; кулдан ясалган чаңгыларда йөгерештеләр.

Палаткалар аерым урамнар булып куелган иде. Һәр урамга мөселманннар яши торган берәр илнең атамасы бирелде. Яшьләребез үзләренең илләре турында сөйләп, урамнарын якладылар. Илнең географик үзенчәлекләре, хуҗалыгы турында сөйләделәр, кайберләре ул илнең традицияләрен сәхнәләштерделәр дә.

Камил хәзрәт белән очрашуда яшьләр үзләрен кызыксындырган сорауларга җаваплар алдылар. Еш бирелгән сораулар мәһер, мәхрам, ата-анага карата мөнәсәбәт, туганлык җепләре, банк системасы, кредит, ипотека мәсьәләләренә бәйле иде. Гомумән, җәмгыятьтәге мөселман өммәтен борчыган мәсьәләләр яшьләребезне дә борчый, дигән фикергә килдек. Әлбәттә, бу мәсьәләләр хакында мәгълүматлар шактый күп һәм төрле, шул сәбәпле алар яшьләргә төгәл барып ирешми. Очрашуда мөмкин булганча бу мәсьәләләр аңлатылды. Шимбә көнне имтихан тапшырдылар.

Гомумән алып, форумның узуы зур көч һәм команданың бердәм булуын таләп итте. Район башлыгы Камил Әсхәт улы, спорт комитеты, районның мәдәният бүлеге бар өлкәдә дә: туклану мәсьәләсе, спорт һәм мәдәни чараларда (олимпиада өчен инвентарь, чараларга күлмәкләр, декорацияләр, проекторлар) безгә зур терәк булдылар. Шуны да әйтеп узарга кирәк: 5 вакыт намаз мәчеттә укылды. Бигрәк тә иртәнге һәм ястү намазларын да мәчеттә уку мөмкинчеле булу – күп кенә яшьләребезгә рух өстәде.

Форумның географиясе арту, әлбәттә, сөенедерә. Яшьләр дә гел берберсен чакырып торалар. Моның да уңай һәм тискәре яклары бар әлбәттә, мәсәлән, тел проблемасы. Делегатлар Татарстаннан гына, шулай ук алар татарлар гына да түгел. Шуңа уртак тел – рус теле. Диннең милләте юк, без һәр кешегә динне ул аңлаган телдә ирештерергә тырышабыз. Бу һич кенә дә татар теленә тискәре караш бар-лыгын аңлатмый, әмма татар теленә багышланган бүтән форумнар, мәсәлән «Татар яшьләре форумы» бар. Шул ук Индонезия, гарәп җирлекләреннән килгән яшьләребез рус телен дә өйрәнеп кенә киләләр, ә без алар аңлый торган телдә аралашырга, динне өйрәтергә тиешбез. Форумның елдан ел кабатлана торган горефгадәтләре бар. «Сабантуй», җомга намазында булу, олимпиада һ.б. Менә бу чаралар барысы да татар телендә генә уза: аларның ачылышы да, барышы да.

Яшьләрне югалтмаска кирәк. Монда алар белән ел дәвамында башка чаралар оештыру да ярдәмгә килә: форумнан соң да очрашулар, табигатькә ял итәргә чыгулар, ел дәвамында төрле әңгәмәләр, фикер алышу клублары оештырулар каралган. Безнең форумнан кала да берничә зур чараларыбыз бар. Алар анда волонтер булып та, оештыручылар булып та бик теләп катнашалар. Шуңа чит төбәктән килүче делегатларыбыз үзләренең еракта яшәүләренә үкенеп тә куялар. Татарстаныбызда төрле яшьләр оешмалары бар, алар төрле чаралар үткәрәләр, ләкин аларның күбесе шәригатькә туры килеп бетми. Яшьләребездә гаурәт төшенчәсе, ир-ат һәм хатын-кыз мөнәнәсәбәте төшенчәләре формалашырга тиеш, исламга хас кануннарны алар аңлап гомер итәргә тиешләр. Аларны саклап һәм шул ук вакытта яшьләргә заманча үз-үзләрен камилләштерү чараларын да без үзебезнең форумыбызга кертергә тырыштык. Бу яктан безнең форумыбыз бик отышлы һәм шул яктан безнең форумыбыз чыннан да дини. Яшьләр арасында: «Шәригать кануннарыннан чыкмыйча да, нинди файдалы ял оештырып була икән», – дип әйтүчеләр дә байтак булды. Шулай ук икенче елга күбрәк килергә сүз бирүчеләрне ишетү, яшьләребезгә бу форумның кирәклеген аңлау бик күңелле. Безнең максат – киләсе форумнарны тагын да кызыклырак итү, заман таләпләренә туры китереп оештыру.

■ **Айгөл Биктимирова**
Социаль үсеш бүлеге җитәкчесе

# Хафса бинте Гомәр разыйаллаһу ганһә




Хафса разыйаллаһу ганһә 606 елда (пәйгамбәрлек килергә 5-7 ел кала) Мәккәдә туган. Ислам динен бик яшьләй, әтисе (Гомәр разыйаллаһу ганһе) белән бергә кабул итә.

Гомәрнең һәм Хәмзәнең Ислам динен кабул итүен ишеткәч, мөһаҗирләр яңадан Мәккәгә кайтырга ашыкканнар. Һәбәштән (Эфиопия) кире кайтучылар арасында Хүнәйс бине Хүзәфә дә була. Өенә кайткач, ул Хафсаның атасына яучылар җибәреп, аңа өйләнә.

Хүнәйс бине Хүзәфә башта Бәдер сугышында, аннары Өхед сугышында катнашкан. Өхед сугышында яраланып, ярасы баштарак төзәлгән кебек булса да, тиздән ялкынсына. Ул Мәдинәдә шул ярадан вафат була.

Гомәр разыйаллаһу ганһе бик яшьләй (Хафсага ул вакытта бары тик унсигез яшь кенә булган) тол калган кызы өчен кайгыра һәм аны тизрәк ышанычлы кулларга тапшырырга, яңадан кияүгә бирергә теләгән. Кызы өчен ул лаеклы сәхабәләрне исенә төшергән.

Ниһаять, озак кына уйлаганнан соң, ул кызын Госман разыйаллаһу ганһегә бирергә карар кыла. Госман күптән түгел генә, Бәдер сугышыннан соң вафат булган хатыны – Пәйгамбәр галәйһис-сәләмнең кызы Рокыяны җирләгән булган. Гомәрнең тәкъдименә җавап итеп, Госман разыйаллаһу ганһү: «Миңа уйларга вакыт бир», – дип әйткән. Әмма берничә көннән алар яңадан күрешкәч: «Мин хәзер өйләнергә теләмим!» – дип җавап биргән.

Шуннан соң Гомәр разыйаллаһу ганһе Әбү Бәкер янына барырга уйлый. Ул аңа да хәлне сөйләп биргән. Әмма Әбү Бәкер бер сүз дә әйтмәгән. Гомәрне бу хәл бик рәнҗеткән, чөнки ул Әбү Бәкер дусты яшь, тәкъва, чибәр кызына өйләнер, дип өмет иткән.

Ике якын дустыннан да уңай җавап ала алмагач, Гомәр разыйаллаһу ганһенең кәефе кырылган. Үзенең кайгысын Мөхәммәд галәйһис-сәләмгә сөйләгән. Мөхәммәд галәйһис-сәләм елмаеп: «Хафсага Госманнан яхшырак кеше өйләнәчәк, ә Госман Хафсадан яхшырак хатын-кызга өйләнсен», – дип әйткән.

Гомәр разыйаллаһу ганһе берничә көн буена бу турыда уйлап йөргән. Шуннан соң Мөхәммәд галәйһис-сәләм аңа: «Хафсаны миңа хатынлыкка бир, ә мин үз кызым Өмме Көлсемне Госманга хатынлыкка бирәчәкмен», – дигән.

3 нче һиҗри елда, шәгъбан аенда Пәйгамбәр галәйһис-сәләм Хафсага өйләнә. Хафсага бу вакытта 20 яшь, ә Пәйгамбәребез галәйһис-сәләмгә 55 яшь була.

Көннәрдән бер көнне Гомәр разыйаллаһу ганһе хатынынннан Хафсаның Пәйгамбәр галәйһис-сәләмне рәнҗеткәнен ишетә һәм тиз арада кызы янына килә. Булган хәлләр турында сораштыра. Хафса: «Чыннан да шулай булды», – дип раслый. Шунда Гомәр разыйаллаһу ганһе: «Мин сине Аллаһның җәзасы һәм Пәйгамбәрнең ачуы турында кисәтәм. Кызым, матурлыгы Пәйгамбәрне сокландырган кыз һәм Пәйгамбәрнең аңа булган мәхәббәте сине сукырайтмасын. Аллаһның Илчесе үзеңне яратмавы турында белгәнсең. Әгәр дә мин булмасам, ул синең белән аерылышкан булыр иде», – дип әйткән. Гомәр разыйаллаһу ганһе Хафсага, көнчелеген басып, Гайшә белән дуслашырга тәкъдим иткән. Ул Мөхәммәд галәйһис-сәләмнән гафу сораган, кызының яшьлек ялгышы җибәрүен таныган.

Әтисенең үгетләүләренә карамастан, Хафсаның яшьлеге һәм буйсынмас холкы һәрвакытта да үзен сиздереп торган. Хатын-кыз көнчелеге түбәндәге вакыйгаларга сәбәпче булган һәм Пәйгамбәр галәйһис-сәләмнең ризасызлыгын тудырган.

Хафса белән Гайшә Пәйгамбәр галәйһис-сәләмгә каршы сүз куешканнар. Булган хәлләрне төрле хәдисләрдә төрлечә бәян итәләр.

1. Гайшәдән (Аллаһ аннан разый булсын) риваять ителә: «Пәйгамбәр галәйһис-сәләм Зәйнәп бинте Җәһеш янында озаккарак тоткарланган һәм аның өендә бал ашаган. Мин һәм Хафса сүз куештык, әгәр Пәйгамбәр галәйһис-сәләм аннан кайтып, берәребез янына керсә, «Синнән мәгафир (яман исле сагыз) исе килә», – дип әйтәчәкбез. Пәйгамбәр галәйһис-сәләм өенә кайтып, аларның берсеннән шул сүзләрне ишеткән һәм җавап итеп: «Мин Зәйнәп бинте Җәһештә бал ашадым. Ант итәм, мин беркайчан да башка болай эшләмәм», – дип әйткән. Шуннан соң Аллаһы Тәгалә Коръәннән әлеге аятьне иңдерә:

**«Ий Пәйгамбәр! Ни өчен син хатыннарыңның яхшы мөнәсәбәтен теләп, үзеңә Аллаһ хәләл кылган нәрсәләрне хәрам кыласың? Аллаһ – Гафу итүче, Рәхмәтле».**

«Тәхрим / Тыю», 66:1

Шулай ук хатыннарына мөрәҗәгать кебек:

**«Ий Хафса һәм Гайшә, әгәр Аллаһка тәүбә итсәгез, әлбәттә, тәүбә итәрлек эшегез булды, сезнең күңелегез үзегезгә вәҗиб булган эштән авышты. Әгәр сез Расүл зарарына ярдәмләшсәгез, дөреслектә, Аллаһ – Ул Расүл галәйһис-сәләмнең хуҗасы һәм ярдәмчеседер, Җәбраил фәрештә аның ярдәмчеседер, мөэминнәрнең яхшылары аның ярдәмчеләредер һәм болардан башка фәрештәләр аңа ярдәмчеләрдер».**

«Тәхрим / Тыю», 66:4

2. Әнәстән (Аллаһ аннан разый булсын) риваять ителгән хәдистә әйтелгән: Пәйгамбәр галәйһис-сәләм Хафсаның өендә Мәрьям исемле кәнизәге белән ялгыз калган. Бу аңа тагын күңелсезлек китергән. Моны белгәч, Хафса: «Әй Аллаһның Илчесе, ни өчен нәкъ минем өйдә?» – дип сораган. Пәйгамбәр галәйһис-сәләм: «Хафса, моннан соң мин үземә аңа кагылуны хәрам кылам. Үтенеп сорыйм, бу турыда беркемгә дә сөйләмә», – дигән. Әмма Хафса тыелып тора алмаган һәм бу турыда Гайшәгә сөйләгән. Шушы уңайдан «Тәхрим / Тыю» сүрәсенең беренче биш аяте иңдерелгән.

Булган хәлләр Пәйгамбәребез галәйһис-сәләмгә нык тәэсир итә һәм ул Гайшә белән Хафсаның янына бер ай дәвамында кермәскә ант итә. Ул бер ай дәвамында аларның өйләренә кермәү генә түгел, хәтта исемнәрен дә телгә алмый, сәхабәләренең берсе дә аларга бәйле булган нәрсәләр турында бер сүз дә әйтмиләр. Шуңа да халык арасында Аллаһның Илчесе хатыннары белән аерылган, дигән хәбәр тарала. Әмма беркем дә бу турыда аның белән сөйләшә башларга җөрьәт итмәгән.

Әлеге кылган эше өчен Хафса бик тә үкенгән. Моннан соң ул беркайчан да хатын-кыз фетнәләрендә катнашмаган, иренең ачуын чыгарырлык гамәлләр кылмаган.

Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм 63 яшендә вафат була. Аның үлеменнән соң Хафса разыйаллаһу ганһә Мәдинәдә кала, Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кыла. Хаҗ һәм гомрә кылудан кала өеннән бик чыгып йөрми. Мөхәммәд галәйһис-сәләмнең вафатынан соң да ул мөселманнар тормышында мөһим роль уйный.

Әбү Бәкер разыйаллаһу ганһе хәлифәлек иткән дәвердә Изге Коръән бер китап булып җыела һәм бу бердәнбер нөсхә була. Ул үзе үк бу беренче кульязманы саклаучы итеп билгеләнә һәм аны үлгәнчегә кадәр үзендә саклый. Аның вафатыннан соң бу нөсхә Гомәр разыйаллаһу ганһегә бирелә һәм ул шәһид булып киткәнчегә кадәр анда саклана. Гомәр разыйаллаһу ганһе нык яралангач, Коръән кульязмаларын сакларга кызы Хафсага тапшыра. Бераз соңрак мөселманнар арасында Коръән уку буенча төрле каршылыклы сораулар туа. Бу хәбәр Хөзәйфә бине Әл-Йәмән исемле сәхабәгә барып җиткәч, ул куркуга кала һәм тизрәк Госман бине Гаффан янына ашыга. Шуннан соң Госман (Аллаһ аннан разый булсын) мөселманнар арасында төрле фикер каршылыклары, бидгать гамәлләр килеп чыкмасын өчен Коръән укуның бердәм формасын расларга карар кыла. Ул мөэминнәрнең анасы Хафсадан бер мосхафка туплар өчен Изге Коръәннең кульязмасын алып тора. Бу мосхаф Зәйд бине Сәбит җитәкләгән Коръән-хафизлар төркеме ярдәмендә туплана. Госман бине Гаффан әзер мосхафның җиде күчермәсен ясап, җиде төбәккә тарата (Мәккә, Мәдинә, Куфа, Басра, Йәмән, Мисыр, Шам). Коръәннең төп нөсхәсе Хафса разыйаллаһу ганһәгә кайтарып бирелә һәм үлеменә кадәр анда саклана. Шуннан соң, васыять итеп абыйсы Габдуллаһ бине Гомәргә тапшырыла.

Гомеренең ахырын Хафса Мәдинәдә ялгызлыкта, гел ураза тотып, намазларын укып үткәрә. Могавия бине Әбү Суфьян идарә иткән чорда, 61 яшендә вафат була. Җеназа намазын аңа Мәрван бине Әл-Хәким укый. Хафса Пәйгамбәр галәйһис-сәләмнең башка хатыннары кебек үк, Җәннәт Әл-Бакый зиратына күмелә.

■ *Сәхифәне Лилия Хәләфетдинова әзерләде*

# Хаҗ турында 3 сорау

Кәгъбә – ул таш бина гына түгел, ә Җирдә салынган иң беренче мәчет. Шуңа күрә дә хаҗ сәфәре мөселманнар өчен бик мөһим вакыйга булып тора. Мәккәгә хаҗ кылырга бару – Ислам диненең 5 баганасының берсе. Хаҗ кылыр өчен мөселман кешесе физик яктан сәламәт булырга, шулай ук финанс яктан юл чыгымнарын каплый алырга тиеш. Әмма бу гыйбадәтнең барыннан да рухи ягы өстенрәк икәнен исебездән чыгарырга ярамый. Хаҗ вакытында һәрбер кешенең Аллаһы Тәгаләгә күбрәк дога кылырга, үзенең кылган начар гамәлләре өчен ярлыкау сорарга, йөрәгендәге кара таплардан арынырга мөмкинлеге бар.



## Ни өчен хаҗилар Мәдинә шәһәрендә 8 көн торалар?

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәләм бу дөньяга 571 елда килеп, аны 632 елда калдыра. Ул бу дөньяда 63 ел гомер кичерә. Шуның 53 елын ул Мәккә шәһәрендә, 10 елын Мәдинәдә яши. Мәдинәне зиярәт кылу – хаҗ яки гомрәнең шарты булып тормый. Әмма хаҗилар озын һәм авыр юл үтеп, шул җирлеккә кадәр килеп җиткәч, Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм яшәгән, укыткан, үзенең вәгазьләрен сөйләгән җирләрне күреп кайтасылары килә. Шулай ук Мәдинә шәһәрендә «мәсҗид ән-нәби» урнашкан. Пәйгамбәребез мәчетендә 40 намаз укуның фазыйләтен һәрбер кешенең ишеткәне бардыр. Бу гыйбадәтне үтәү өчен хаҗилар Мәдинәдә 8 көн торырга күнеккәннәр. 5 вакыт намазны 8 көн рәттән укыгач, 40 намаз була. Ә Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәләм болай дип әйткән: «Минем мәчетемдә 40 тапкыр намаз укыган кеше җәһәннәм уты газабыннан һәм бу дөньяда мөнафикъ булудан имин булачак» (Имам Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан).

## Кәгъбәне 7 тапкыр тәваф кылуның сере нәрсәдә?

Тәваф кылу – мөселманнарның бердәмлеген саклау, аларның ихласлыкларын арттыру да булып тора. 7 саны бу очракта да үзенә бер төрле мәгънә йөртә. Күкләрнең саны җиде, нәфеснең дәрәҗәләре дә җиде. Һәрбер әйләнеп чыгу нәфеснең түбән дәрәҗәсеннән югарысына күтәрелү дигәнне аңлата. Мондый күчеш «нәфсүл-әммәрадән» (начарлыкка чакыра торган нәфестән) «нәфсүл-мутмәиннәгә» (югары, тынычланган нәфескә) таба бару. Иң югарысы «нәфсүл-кәмилә», ягъни камил нәфес була. Тәваф – безнең көчле системага корылган һәм бердәм яшәп килгән галәм төзелешенә аллегория дә сыман: күк йөзе, кояш, йолдызлар h.б. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйткән: **«Җиде кат күк вә җир һәм күкләрдә вә җирдә булган һәр мәхлук Аллаһны мактап тәсбих әйтәләр, Аллаһны мактап тәсбих әйтмәгән нәрсә юк, күзгә күренгәне вә күренмәгәне Аллаһны зекер итәдер, ләкин сез аларның тәсбихләрен аңламыйсыз. Әлбәттә, Аллаһ Миһербанлы вә Ярлыкаучы».**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:44

Тәваф вакытында мөселманнар тыныч халәттә – курку һәм өмет арасында булырга тиешләр. Ибраһим галәйһис-сәләм белән Исмәгыйль галәйһис-сәләм Кәгъбәне төзегән вакытта аны тыныч кына әйләнгән кебек, хаҗилар да тәваф вакытында тыныч кына әйләнеп, үзләренең йөрәкләрен, күңел бозыклыкларын пакьлиләр.

## Тәваф кылу нәфел намаз укуга караганда саваплыракмы?

Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһис-сәләм үзенең бер хәдисендә: «Кәгъбә тирәли тәваф кылу – шулай ук гыйбадәттер. Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә тәваф вакытында сөйләшүне рөхсәт итте. Әмма сөйләшү бары тик яхшы әйбер турында гына булырга тиеш», – дип әйткән. Бу хәдистән чыгып, тәвафның гыйбадәт икәнен һәм нәфел намаздан түбән булмаган гамәл икәнен әйтә алабыз. Фарыз тәваф – фарыз намаз кебек, ә өстәмә тәваф – өстәмә намаз кебектер. Әмма мөселман кешегә кайсы фазыйләтлерәк соң: намазмы әллә тәвафмы? Бу сорауга Коръәнне тәфсир кылучы Габдуллаһ бине Габбас: «Мәккәдә яшәүчеләр өчен намаз, ә читтән килүчеләр өчен тәваф хәерлерәк», – дип җавап кайтарган. Сәгид бине Җөбәйр дә шул ук фикерне хуплаган. Шулай ук Гайшә анабыздан түбәндәге хәдис китерелә: «Пәйгамбәребез: «Кәгъбәгә карап тору – шулай ук гыйбадәттер», – дип әйтте». Аллаһы Тәгалә һәрберебезгә бу гыйбадәтне үтәргә насыйп әйләсә иде.

**Islam-today**

# Кеше төшендә киләчәктә булачак вакыйгаларны күрә аламы?

**Сорау: Кеше төшендә күргәннәргә карап, киләчәкне юрый аламы?**

**Җавап:** Төшләр – тормышыбызның иң кызыклы табышмакларыннан берсе булып торалар. Бу мәсьәләгә карата кызыксыну бик борынгыдан килә. Сәхабәләр дә төшләрендә күргән әйберләрнең тормышка ашуын күргәч, бу әйбер белән кызыксына торган булганнар. Моның турында кайбер хәдисләрдә дә әйтелә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәләм өч төрле төш була ала дигән: рахмәни, нәфсәни һәм шәйтани. Ул галәйһис-сәләм: «Төшләр өч төрле була: Аллаһы Тәгалә тарафыннан булган төш; шомга, хафага сала торган шайтаннан булган төшләр; һәм кеше өнендә күргән, уйлап йөргән әйберләрен йоклаган вакытында төштә күрүе» (Имамнар Бохари һәм Мөслим).

Шулай ук Пәйгамбәребез Мөхәммәд: «Әгәр берәрегез начар төш күрсә, сул як җилкәсе ягына өч тапкыр төкерсен, аннан соң Аллаһтан шайтанның зыяныннан саклау эзләсен («Әгүзе»не әйтсен), шуннан соң икенче якка борылып ятсын», – дип әйткән (Имам Мөслим).

Аллаһы Тәгаләнең кодрәте, рәхмәте чиксез. Ул Үзе теләгән кешегә ризык та, бәрәкәт тә бирә ала һәм шулай ук Үзе теләгән кешедән бәрәкәтне ала ала. Кешегә әзерләнгән нигъмәтләр өндә генә түгел, төш вакытында да килергә мөмкин, ягъни Аллаһы Тәгалә Үзенең аять-билгеләрен теләсә-кайсы вакытта күрсәтә ала. Аллаһы Тәгалә төш аша ниндидер яхшы яки начар әйберне күрсәтә. Әгәр яхшылык булса, бу үзенә күрә бер бүләк була, әгәр начарлык күренсә – кисәтү. Мондый төр төшләрнең максатлары да төрле була ала: кешенең игътибарын нәрсәгә дә булса җәлеп итү, гыйбадәт кылырга теләк тудыру, гөнаһлы гамәлдән саклап калу, тыелган нәрсәләрне күрсәтү. Танылган ислам галиме Ибне Сирин дә үзенең бер китабында төшләрне юрау авыр хезмәт, дип яза. Бу фән белән шөгыльләнүчеләр күп укыган булырга, эшләренә җитди һәм җаваплы карарга тиешләр, ди ул. Бер кызыклы факт та бар: төш юраучылар әйтүенчә, хафалы төшләр, дөреслектә, бик тә файдалы була алалар. Бу төшләр безнең баш миебезнең безгә карата кисәтү символлары да булып тора. Ягъни тормышыбызда игътибар итәргә кирәкле нәрсәләргә төштә басым ясала. Әмма төш юраучылар шулай ук бу хафалы төшләр турында бик озак уйламаска да тәкъдим итәләр, чөнки начар төш турында озак уйлап, кеше артык борчуга батарга мөмкин, ә ахырдан бу психикага да тискәре йогынты ясый ала. Ни генә булмасын, һәрвакытта да Аллаһы Тәгаләгә генә тәвәккәл кыларга кирәклеген исебездән чыгармаска кирәк. Аңа ихлас тәвәккәллек кенә чын мәгънәсендә тынычлык, бәхет һәм котылу бирә ала.

**Islam-today**

## Җәбраил галәйһис-сәләм саткан дөя

Беркөнне Гали бине Әбү Талиб өенә кайткач, анда ашарга берни дә булмый. Хатыны Фатыйма аңа өйдә нибары 6 вак тәңкә барлыгын хәбәр итә. Гали шуларны алып, базарга юнәлә. Юлда ул бәхәсләшүче ике кешене очрата. Бер кеше мөселманны якасыннан тотып: «Йә миңа акчаны кайтарасың, йә без судка казый янына барабыз», – дип әйтә. Бу мөселман бу кешедән 6 тәңкә әҗәткә алып торып, бераз вакыт бирүен сорый, әмма ризалык алмый. Гали сумманың 6 тәңкә икәнен белгәч, ул үз акчаларын бу мөселманга бирә.

Өенә кайтып, үзенең бернәрсә дә алмавын һәм бер мөселманны судтан коткарып калганын сөйли. Бу хәлләрдән онытылып торыр өчен, кабаттан урамга чыга һәм Пәйгамбәр янына юнәлә. Юлда аңа дөясен сатарга алып баручы бер кеше очрый. Галигә бу дөяне сатып алырга куша һәм аның акчасы булмагач, ул аны аңа 100 дирһәмгә әҗәткә сата. Гали дөя белән юлын дәвам итә һәм аңа тагын бер кеше очрап: «Дөяңне сатмыйсыңмы? Мин аны синнән 300 дирһәмгә алыр идем», – дип әйтә. Гали дөяне сатып, 100 дирһәм әҗәтен кайтара, базардан ризыклар сатып алып, өенә кайта.

Бу хәлләрне Пәйгамбәргә сөйләп биргәч, Мөхәммәд галәйһис-сәләм: «Беләсеңме, сиңа дөяне Җәбраил сатты, ә сатып алучысы Микаил иде. Аллаһы Тәгалә сиңа теге мөселманны аның әҗәтеннән азат иткәнең өчен арттырып кайтарды», – дип җавап бирә.

## Без югалткан хәзинәләр

Пәйгамбәребез Мөхәммәд үлеме алдыннан бик каты авырган вакытында аның янына Җәбраил фәрештә килә. Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм аннан: «Минем вафатымнан соң җиргә кабат төшәсеңме?» – дип сораган. Ул: «Син бу дөньядан киткәч, мин бу дөньяга тагын 10 тапкыр 10 төрле хәзинәне алырга төшәчәкмен», — дип җавап кайтарган. «Нинди хәзинәләр», – дип сорагач, ул: «Иң беренчеләрдән булып, бу җирдән бәрәкәтне алачакмын. Аннан соң кешеләрнең йөрәкләрендәге бербереенә карата булган мәхәббәтне алам. Өченче әйбер итеп туганнар арасындагы яратуны, дүртенче – хакимнәрнең гаделлеген алам. Бишенче әйбер итеп хатын-кызларның оят хисен һәм намуслылыгын алачакмын. Аннан соң фәкыйрь кешеләрнең сабырлыгын, галимнәрнең тәкъвалыгын, бай кешеләрнең юмартлыгын алачакмын. Тугызынчы – Коръән Кәрим булачак. Унынчы һәм соңгы әйбер – мин кешеләрнең иманнарын (Аллаһка ышануны) алачакмын», – дип җавап кайтарды.

Елдан ел бу хәдистә килгән хәзинәләребез югала бара. Һәм бер көнне кешеләр «Бисмилләһ»не дә әйтә алмаячаклар. Йөрәкләребездә булган иманыбызны саклап, Пәйгамбәребезгә ияреп, Аллаһның китабына таянып, аның буенча гамәл кылып яшәргә тырышырга кирәк.

## Гафу итә белү югалса

Бервакыт өч кеше Гомәр Әл-Хаттаб янына бер көтүчене алып киләләр һәм бу кешене җәзаларга кушалар.

– Йә, Гомәр, мин көтүчемен. Минем бер сарыгым аларның әтисенең бакчасына кереп, бераз чирәм ашаган. Моны күреп, ул сарыкка таш аткан һәм минем сарыгым вафат булды. Мин дә моны күреп, аңа таш аттым, әмма ул да вафат булды, – дип аңлатып бирә көтүче.

– Болай булгач, сиңа тиешле җәза бирелергә тиеш, – дип әйтә Гомәр Әл-Хаттаб.

Көтүче әтисеннән калган мирасны энекәшенә тапшырып килүне үтенеп, Гомәрдән 3 көнгә рөхсәт сорый. Аны монда беркем дә белмәгәнлектән, ул бармагы белән төртеп Пәйгамбәребезнең сәхабәсе Әбү Заррага күрсәтә һәм: «Бу кеше минем өчен йолым булачак», – дип әйтә. Әбү Зарра риза була һәм көтүче кайтып китә. 3 көн үткәннән соң көтүче сүзендә торып, йөгереп Гомәр каршына килә. Гомәр: «Син бит килмәскә дә мөмкин идең», – дигәч, ул: «Мин Мөхәммәд өммәтендә тугрылык калмаган, дип әйтүләреннән курыктым», – дип әйтә. Әбү Зәрра да: «Мин Мөхәммәд өммәтендә ышаныч калмаган, дип әйтүләреннән курыктым», – дип әйтә. Моны күреп гаепләүче өч кеше дә бу көтүчене кичерергә булалар. Гомәр алардан моның сәбәбен сорагач: «Без Мөхәммәд өммәтендә гафу итүчеләр калмады, дип әйтүләреннән куркабыз», – дип әйтәләр.

## Пәйгамбәрне үзеңә караганда да ныграк ярату

Хәзрәти Гомәр Расүлуллаһ белән юлда булганда: «Әй, Аллаһның илчесе, дөреслектә, мин сине үземнән кала бар нәрсәдән дә ныграк яратам», – дип әйтә. Мөхәммәд пәйгамбәр: «Мин синең өчен үзеңә караганда да сөеклерәк булмыйча, иманың камил бумас», – дип җавап кайтара. Гомәр бу сүзләрне ишеткәч: «Дөреслектә, хәзер мин сине үземә караганда да ныграк яратам», – дип әйтә.

Пәйгамбәребезнең хәдисе буенча, без аны үзебезгә, әти-әниләребезгә һәм балаларыбызга караганда да ныграк яратырга тиешбез. Һәм бары тик бу төр ярату гына Аллаһның рәхмәтенә һәм камил иманга китерә ала.

Әлбәттә, бу ярату көнелдәге хис булып кына калырга тиеш түгел. Яратучы кеше үзенең яраткан кешесенә охшарга тырышырга тиеш. Расүлуллаһның тормыш рәвешенә иярергә тырышу – үзебезне тәрбия кылуда иң яхшы юл булып санала, чөнки ул иң яхшы үрнәк һәм галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелгән зат иде. Димәк, Пәйгамбәр галәйһис-сәләмнең ярату рәвешен, аның югары әхлагын, кылган гамәлләрен үзебезнең тормыш моделе итеп сайларга кирәк. Ул читләшкән гамәлләрдән читләшеп, ул хуплаган гамәлләр кылып, ул сөйләшкән темаларга сөйләшеп, гыйлем юлында булырга тырышырга кирәк. Аллаһның илчесен яратып, аннан үрнәк алучылар – югары бәхеткә ия кешеләр.

## Мөселманнарны «ин шә Аллаһ» диергә кем өйрәткән?

Ин шә Аллаһ – Аллаһы Тәгалә теләсә. Бу сүзнең шул рәвешле кулланыла башлавының үз тарихы бар.

Расүлуллаһның пәйгамбәрлеге башында Мәккә кабиләләре аңа дошманлык белдерә, Мөхәммәднең пәйгамбәр булуына ышанмый. Мәккәлеләр Пәйгамбәргә өч сорау биреп, аның ялганчы икәнен дәлилләячәкбез, дип сөенәләр. Бу сораулар мондый була: «Мәгарәдә калган егет турында сөйлә», «Мәгъриб белән мәшрикъ хакиме турында сөйлә», «Рух турында сөйлә».

Мөхәммәдкә бу сорауларны биргәч, ул: «Мин сезгә иртәгә әйтермен», – дип җавап кайтарган. Әмма ул «ин шә Аллаһ» димәгән. Унбиш көн дәвамында Расүлуллаһка вәхи иңдерелми. Унбишенче көнгә сүрә иңдерелә. Ул Пәйгамбәребезгә бирелгән ике сорауга җавап була. Аллаһы Тәгалә болай ди:

**«Әгәр бер эшне эшләргә теләсәң: «Мин иртәгә бу эшне эшләрмен», – димә. «Мәгәр Аллаһ теләсә эшләрмен», – дип әйт! «Әгәр Аллаһы Тәгалә теләсә», – дип әйтергә онытсаң, хәтереңә килгәч тә: «Аллаһ теләсә», – дип әйт! Янә әйт: «Бу егетләрнең барча хәлләрен Раббымның миңа белдерүе өметледер».**

«Кәһаф/ Тау тишеге» 18:23-24

Шул рәвешле «ин шә Аллаһ» сүзләре сөйләмебезнең аерылгысыз өлеше булып китә.

## Гыйлемгә омтылучыларның юлына фәрештәләр канатларын җәяр

Бервакыт берәү Мәдинәдән Шамга Пәйгамбәребез галәйһис-сәләмнең сәхабәсе булган Әбү Дәрданы күрергә килгән. Әбү Дәрда бу таныш булмаган кешенең үз янына килүен белеп гаҗәпләнгән. Теге кеше исә: «Мин синнән Мөхәммәд галәйһис-сәләмнең бер хәдисен белергә килдем», – дигән. Әбү Дәрда моннан төпченеп: «Син минем яныма сатулашырга килдеңме?» – дип сораган. Теге кеше аның соравына җавап итеп:

«Юк, мин синнән бу хәдисне өйрәнергә генә дип килдем», – дигән. Шуннан соң Әбү Дәрда аңа Пәйгамбәребез галәйһис-сәләмнең түбәндәге сүзләрен ирештергән:

«Гыйлем алырга юлга чыккан кешене Аллаһы Тәгалә җәннәткә илтә торган юл буйлап җибәрер. Белемгә омтылучыга ризалыкларын белдереп, фәрештәләр канатларын аның юлына җәярләр. Җир һәм күк ияләре, хәтта диңгездәге балыклар да Аллаһтан аны гафу итүен ялварырлар. Гыйлемле кеше белән гыйбадәт кылган белемсез кешенең хәләте йолдызлар янында яктырып балкыган айның хәләтенә тиң. Галимнәр – пәйгамбәрләрнең варислары. Пәйгамбәрләр мирас итеп үзләреннән соң алтын да, көмеш тә калдырмаганнар, фәкать гыйлем калдырганнар. Гыйлемгә ия булган кеше бөек нигъмәткә ирешер» (Тирмизи).

## Хаҗәр һәм Зәм-зәм чишмәсе

Зәм-зәм чишмәсенең тарихы турында сөйләгәндә, Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәләм: «Исмәгыйльнең әнисен Аллаһы Тәгалә кичерсен! Әгәр ул ашыкмаса (Зәм-зәм чишмәсеннән су җыймаган булса), Зәм-зәм бик зур чишмә булган булыр иде», – дип әйткән (Бохари, Әхәдисуль-әнбия, 9).

Ибраһим (аңа Аллаһның сәламе булсын) хатыны Хаҗәр белән улы Исмәгыйльне Фәләстыйннан Мәккәгә илтә. Ул вакытларда Мәккә кешеләр яшәмәгән эссе чүл була. Анда Хаҗәр үзенең күкрәк баласы белән бары тик Аллаһы Тәгаләнең карамагында кала. Берничә көннән соң аның ашарына ризыгы, эчәренә суы бетә. Улы сусаудан җиргә ятып өзгәләнә. Баласының болай өзгәләнүен ана кеше тыныч кына карап тора алмый. Ул Сафа калкулыгына йөгереп менә. Тирә-ягына карана, ләкин анда үзенә ярдәм итәрлек беркемне дә күрми. Шуннан соң каршы яктагы Мәрва калкулыгына йөгереп менә, ләкин анда да бер тере җанны да очратмый. Ике калкулык арасын ул шулай җиде тапкыр йөгереп үтә. Мәрва калкулыгына соңгы мәртәбә күтәрелгәндә Хаҗәр тавыш ишетә, аннан ярдәм сорый. Шул чакта фәрештә пәйда була һәм үзенең үкчәсе (яки канаты) белән җирне тишә. Әлеге тишкән җирдән Зәм-зәм чишмәсе бәреп чыга.

# Гыйлем алуның фазыйләтләре

Коръән

اقْرَأْ بِاسْمِ رَبِّكَ الَّذِي خَلَقَ

дигән сүзләр белән, ягъни: «Ий, Мөхәммәд, һәрнәрсәне халык кылучы Раббыңның исеме белән Коръәнне укы», – дигән сүзләр белән башлана. Беренче сүзләр, беренче боеру укырга, ягъни белем алырга боеру була. Кеше Аллаһы Тәгаләгә генә гыйбадәт кылу өчен яратыла. Бу хакта Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә кешенең исенә төшерә. Ничек гыйбадәт кылырга, ничек яшәргә тиеш икәнлеген аңлаткан боерулар кешегә яшәү рәвешен билгеләр һәм бу Ислам дине була. Кеше Ислам диненең хаклыгын белмәве сәбәпле, гыйбадәтен тиешенчә кылмый, яшәү рәвешен тиешенчә алып бармый. Ягъни аның бөтен бәласе – белемгә тиешенчә игътибар бирмәвендә. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Аллаһ Үзеннән башкага гыйбадәт кылмаска әмер кылды, бу Ислам дине – хак дин, ләкин күп кешеләр белмиләр».**

«Йосыф», 12:40

Аллаһы Тәгалә бу аяти-кәримәдә адәм баласына Үзеннән башкага гыйбадәт кылмаска боера, Ислам диненең генә хак дин булуын, боерыкларны үтәүнең тиешлеген һәм Ислам диненең хаклыгын күпләрнең белмәгәнлеген исләренә төшерә. Гыйбадәтләрне тиешенчә үтәү һәм Ислам диненең хаклыгын аңлау өчен Аллаһы Тәгаләдән курку тиешенчә булырга тиеш. Ә инде Аллаһтан тиешенчә курку өчен тиешенчә белемгә ия булу кирәк. Аллаһы Тәгалә:

**«Ий, мөэминнәр, Аллаһтан каты куркыгыз, Аның хөкемнәрен бозудан бик нык сакланыгыз һәм Коръән белән гамәл кылып, чын мөселман булган хәлегездә генә үлегез!»** – дип әйтә.

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:102

Гыйлемгә омтылу гомер-гомергә безнең халыкка хас сыйфат булган. Әмма соңгы вакытта гыйлем алу белән диплом алуны бутаучылар күбәйде. Нәтиҗәдә дипломлы кешеләр күп, ә белемле кешеләр аз. Кеше үзенең белеме булмаган нәрсәләр турында бәхәс алып бара. Бүген китаплар күп. Мәсәлән, кибеттән күп кенә табиплык турында китаплар алып, шуларны укыган кешенең, медицина институтын тәмамлап кайткан кешене өйрәтүе, яисә мәктәпне көчкә-көчкә тәмамлаган кешенең профессорны өйрәтүе акылга сыймый.

Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

**«Әйт, белүчеләр белән белмәүчеләр бертигез булырлармы?»**

«Зүмәра / Халык Төркеме», 39:9

Кешегә беренче боерылган нәрсә – белем алу. Һәм ул аңа омтылырга тиеш. Без балаларыбызны мәктәпләргә илтәбез. Фәлән кеше оста укыта дип, фәлән кешегә илтмибез бит. Дини белем белән дә шулай ук: билгесез кешедән белем алганчы, мәчет-мәдрәсәләрдә белем алу яхшырактыр. Башлангыч белемне, әлбәттә, бала ата-анадан алырга тиеш. Әгәр дә ата-ананың тиешле белеме булмаса, баланы мәчет-мәдрәсәләргә, яисә ышанычлы кешеләргә илтү яхшырак.

Белем алуда белмәүче кеше үзенең яшенә карамастан, белемле кешегә иярергә тиеш, хәтта ул аңардан яшьрәк булса да. Коръән Кәримдә Ибраһим галәйһис-сәләм үзенең әтисенә белем өйрәтергә тәкъдим ясый:

**«Ий, әтием, Аллаһтан миңа гыйлем килде, ул гыйлем синдә юк, миңа ияр, мин сине туры юлга күндеремен».**

«Мәрьям», 19:43

Белемне үзеннән түбәнрәк дәрәҗәдә торучыдан да, хәтта кош, хайван кебек башка җан ияләреннән дә алырга мөмкин. Коръәндә Аллаһы Тәгалә бу хакта Сөләйман галәйһиссәләм белән һуд-һуд кошы арасында барган сөйләшү мисалында күрсәтә. Һуд-һуд кошы югала һәм табылганнан соң Сөләйман галәйһис-сәләм аны җәзага тартырга уйлагач, һуд-һуд кошы болай дип әйтә:

**«Һәм әйтте: «Ий, патшам, мин ерак җиргә барып син белмәгәнне белдем һәм Сәба шәһәреннән сиңа хак булган яңа хәбәр белән килдем».**

«Нәмел / Кырмыска», 27:22

Монда һуд-һуд кошының Сөләйман галәйһис-сәләм белмәгәнне белгәнлеге күрсәтелә. Һәм Адәм галәйһис-сәләмнең уллары Кабил һәм Һабил мисалында карганың кешене өйрәтүен күрсәтә:

**«Аллаһ Кабил янына бер карга җибәрде, ул карга Кабилгә җирне казып күрсәтте, ягъни Һабилнең гәүдәсен күмәргә. Карганы күргәч, Кабил: «Һай, миңа үкенеч! Каргадан да көчсезрәк идемме әллә? Карга белгәнне белгән булсам, кардәшемнең гәүдәсен ничә көннәр күтәреп йөрмичә, шунда ук күмгән булыр идем», – дип, бу эшеннән үкенүчеләрдән булды».**

«Мәидә / Аш Яулыгы», 5:31



Бүген дөньяви белем нык алга китте. Кеше бу белемгә, күпчелек очракта, үзеннән күпкә түбән булган җан ияләрен тикшереп, күзәтеп ирешә. Мәсәлән, кошларның очышына карап очкычлар, ягъни самолетлар уйлап табылды. Гади генә бөҗәкләр медицинада зур-зур ачышлар ясалуга сәбәп булды.

**«Ий, кешеләр сезгә белемнән бик аз өлеш бирелде».**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:85

Аллаһы Тәгалә «белемнән бик аз өлеш бирелде» ди һәм бу аз өлеш тә бөтен кешегә дә бирелми. Бирелгәннәр бирелмәгәннәргә үзләренең белемнәрен ирештерергә тиешләр, ягъни гавәм халыкны укытырга, шәригатьне өйрәтергә тиешләр. Белем бирелмәгәннәр дә бирелгәннәрдән үзләренә тиешлесен сорарга тиешләр, ягъни мөмкинлек табып, белем алырга тиешләр.

Дин гыйлемендә чын галимнәр дөньяда бик азлар. Бездә ел саен җәй көннәрендә ястү намазы турында, Рамазан ае җәйге чорга керү сәбәпле тәравих намазларын уку, сәхәр ашау турында бәхәсләр куертыла. Яңа һиҗри айның ничек башлануы шәригатьтә билгеле булуга карамастан, ел саен гает көннәре турында бәхәс бара. Бу бәхәс яңа ай туганны күрү сәбәпле түгел, бәлки ай башланырга атна-ун көн кала башлана. Бу бәхәс, күргәнебезчә, чын галимнәр сүзенә дәлилләп түгел, бәлки диндә дәлиле булмаган бәхәс, ягъни шайтан вәсвәсәсе генә. Фәтвалар бирергә ашыгырга кирәк түгел. Дөрес фәтва бирмичә гөнаһка гына батуың мөмкин. Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын): «Кем белеме булмаган көенчә фәтва бирсә, шул сәбәпле кылынган гөнаһ фәтва бирүчегә төшә», – дип әйткән.

Сәхабәләр сорауга җавап бирергә ашыкмаганнар, башка кешедән сорарга куша торган булганнар. Гали (Аллаһ аннан разый булсын): «Мине ике кеше һәлак итә: оятын югалткан галим һәм үзен тулысынча гыйбадәткә багышлаган надан», – дип әйткән.

Белемсез фәтвалар бирелү заманның бозыклыгын, халыклардан белемнең китүен һәм Ахырзаманның якынаюын күрсәтә.

Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын): «Чынлыкта, Аллаһ белемне Үзенең колларын белемсез калдыру белән алмый, бәлки ул белем ияләрен алу белән белемне ала. Һәм белемгә ия булучыларның берсе дә калмагач, кешеләр үзләренә җитәкче итеп наданнарны сайлап куячаклар. Ә алар исә бирелгән сорауларга белемсез рәвештә җаваплар бирәчәкләр, нәтиҗәдә үзләре дә туры юлдан тайпылачаклар, башкаларны да туры юлдан яздырачаклар», – ди.

Милләтебезнең бүгенге көндә иң зур проблемасы – дини белемнең җитәрлек булмавы. Кеше бөтен нәрсәдән дөнья малын өстен куя, шул сәбәпле туганлык җепләре өзелә, гаиләләр таркала, зина, эчкечелек чәчәк ата, милли горурлык юк дәрәҗәсендә, ягъни кеше хайваннан да түбәнрәк булган тормыш алып бара.

Мөгаз бине Җәбал болай дип әйткән: «Белем алыгыз! Чөнки Аллаһ ризалыгын алу өчен белем алу – Аннан куркуның билгесе, белемгә омтылу – гыйбадәт, башкалар белән нәрсә дә булса өйрәнү – тәсбих, белем алу – җиһад, белемсезгә белем өйрәтү – сәдака, аңларлык кешеләргә белем тапшыру – Аллаһка якынаю чарасы. Белем ялгыз вакытта әңгәмәдәш, дус булачак, дингә юлны күрсәтәчәк, авырлыкларга сабыр итәргә өйрәтәчәк. Белемнәре сәбәпле Аллаһ кайбер кешеләрне җитәкче итеп күтәрәчәк, башкалар аларга ияраячәкләр. Белем турында фикерләү – уразага, башкалар белән белем алу – төнге намазга тиң. Ул кешегә Аллаһка итагать итәргә, Аңа гыйбадәт кылырга, туганнар белән элемтәдә торырга, харам һәм хәләлне белергә булыша. Белем – идарәче, ә гамәл аңа ияргүче. Ул бәхетле кешеләргә бирелә, ә бәхетсез кешеләр аннан мәхрүм кала».

Аллаһы Тәгалә һәммәләребезгә дә иман байлыгы, саулык-сәламәтлек, бәрәкәтле тормыш насыйп итсен, хәерле белем, милләтебезнең туры юлдан баруын һәм дә Аллаһның рәхмәтендә булуын насыйп итсен.

■ **Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиев, Яр Чаллы шәһәренең «Ак мәчет» мәдрәсәсе директоры**

# Яңгыр вакытында кылына торган сөннәтләр

Күз җитә. Димәк, көннәр йә кояшлы һәм матур, йә караңгы һәм яңгырлы булачак. Яңгыр яуганын күпләребез яратып бетерми, шуңа да аннан качу урынын эзли башлыйбыз, кемдер кулчатыр күтәреп йөри, кемдер, гомумән, өеннән чыкмаска тырыша. Шушы ыгы-зыгы вакытында күпләребез яңгырның да Аллаһы Тәгаләнең бер нигъмәте икәнен онытып җибәрәбез бугай. Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнең сөннәте буенча, яңгыр вакытында да үз-үзеңне тоту кагыйдәләре бар икәнен беләидегезме? Ә яңгыр яуганда кылынган доганың кабул булуын? Бу мәкаләбездә без сезнең белән кайбер сөннәтләр турында, нинди дога кылырга кирәклеге хакында сөйләшеп китәрбез.

## Коръәндә яңгыр турында

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә яңгыр турында ике төрле мәгънәдә искә алып, болай дип әйтә:

**«Вә Ул – Аллаһ рәхмәте белән яңгыр алдыннан җил җибәреп, кешеләрне шатландырадыр, ул җилләр кирәк җиргә болытларны алып килерләр, вә Без сезгә болытлардан пакь су иңдердек».**

«Фуркан / Аеручы», 25:48

Ә «Әхкаф» сүрәсендә яңгыр турында мондый аять китерелә:

**«Алар үзләренә газап алып килә торган болытны күргәч: «Бу болыт безгә яңгыр алып килә», – диделәр. Һуд: «(Бу яңгыр түгел) бәлки ул сез ашыктырып сораган газабыгыздыр ки, анда рәнҗетүче каты газап бардыр», – дип әйтте».**

«Әхкаф / Комлык», 46:24

Беренчесендә Аллаһы Тәгалә яңгырны Үзенең колларына нигъмәт итеп, җибәрә. Ул яңгыр безнең иген кырларыбызга, үзебезнең бакчаларыбызга, кош-кортларга, җәнлекләргә ирешеп, бүләк буларак ява.

Икенче очракта исә яңгыр – табигый бәлаказалар рәтенә кергән газаплау чарасы булып тора. Һәм чыннан да, дөнья буенча да, Республикабызның күп кенә районнарында да яңгыр аркасында бәлага тарыган авыллар, шәһәрләрне күрергә була. Аллаһы Тәгалә бөтен әйберне дә контрольдә тота. Бер мизгел эчендә яхшы һава торышын Ул кешеләргә зыян сала торган итеп кыла ала. Ул хәерле халәтне начарга һәм начар халәтне хәерлегә үзгәртә ала. Аллаһы Тәгалә бер үк әйбер белән кешегә файда китереп, икенче кешегә шул ук әйбер белән зыян сала ала.

Моңа мисал булып, әлбәттә, яңгыр да тора. Аның ике яклы табигате турында югарыда китерелгән аятьләрдән укып белеп була. Шулай ук бу очраклар чагылган вакыйганы хәдисләрдән дә укып белеп була.

Әнәс разыйаллаһу ганһе болай дип сөйли: «Җомга көнне Аллаһ Расүле галәйһис-сәләм кешеләргә ниндидер сүз белән мөрәҗәгать иткәндә, мәчеткә бер кеше керде һәм болай дип сорады: «Әй Аллаһ Расүле! Малларыбыз һәлак булды, су бетте, Аллаһка дога кыл: Ул безгә яңгыр бирсен». Бу үтенечкә каршы Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм кулларын күтәрде һәм болай дип дога кылды: «Аллаһым! Безгә мул итеп яңгыр бир. Аллаһым! Безгә мул итеп яңгыр бир». Аллаһ белән ант итәм, күк йөзендә кечкенә генә бер болыт та күренми иде. Шулчак тау артыннан калкан рәвешендәге бер болыт күренде. Бу болыт күкнең уртасына җиткәч, киңәйде. Аннан яңгыр яуды. Бер атна кояш күрмәдек. Киләсе җомга ишектән тагын шул кеше керде һәм «Әй, Аллаһ Расүле! Бөтен җирне су басты, игеннәр һәм маллар әрәм булды», – диде. Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм тагын кулларын күтәрде һәм болай дип дога кылды: «Аллаһым! Тирә-юнебезгә яудыр, өстебезгә яудырма. Аллаһым! Биек калкулыкларга, аланнарга һәм агачлыкларга яудыр» (Имам Бохари).

## Яңгыр вакытында кылына торган догалар

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәләм яңгыр килер алдыннан була торган җил вакытында һәрвакыт борчыла торган булган. Ул яңгырның ике яклы табигате бар икәнен истә тотып шулай эшләгән. Аннан: «Ник шулай борчулысың?» – дип сорагач, ул: «Мин моның минем өммәтемә газап булып килүеннән куркам», – дип җавап кайтара торган булган.

Ә яңгыр яуган вакытта Пәйгамбәребез түбәндәге догаларны кылган:

**«Әллаһүммә инни әс-әлүкә хайраһә вә хайрә мәә фиһә вә хайра мәә урсиләт биһи, вә әгүзү бикә мин шәрриһә вә шәрри мә фиһә вә шәрри мә урсиләт биһи».**

Тәрҗемәсе: «Аллаһым, мин Синнән (яңгырның) хәерлесен, яңгыр эчендә булган хәерне һәм ул алып килгән нигъмәтне сорыйм. Һәм мин бу (яңгырның) зыянынннан, аның эчендә булган зыяннан һәм ул алып килә торган зыяннан Сиңа сыенам».

Дога кылганнан соң, ул яңгырның ничек яуганына игътибар иткән. Һәм әгәр дә ул яңгыр тыныч, иминлек китереп яуса, Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм урамга чыгып яңгыр астында тора торган булган. Аннан: «Ни өчен болай эшлисең», – дип сорагач, Пәйгамбәребез: «Дөреслектә, бу яңгыр әле генә минем Раббымнан иңдерелде», – дип җавап кайтара торган булган.

Шулай ук яңгыр вакытында Пәйгамбәребез:

**«Әллаһүммә сайибән нәәфиган»,** ягъни «Аллаһым, бу яңгыр хәерле нигъмәтләр генә алып килсен», – дип дога кыла кылган.

Көчле яңгырлар вакытында югарыда әйтеп үтелгән доганы кылган:

**«Әллаһүммә хәвәләйнә вә лә галәйнә», ягъни «Аллаһым! Тирә-юнебезгә яудыр, өстебезгә яудырма».**

Яшен яшьнәүләр, күк күкрәүләр булганда Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм түбәндәге доганы кабатлаган:

**«Әллаһүммә ләә тәкътүлнә би гадабикә, вә ләә түһликнә би газәбикә, вә гаафинә каблә зәлик»**

Тәрҗемәсе: «Аллаһым, безгә ачуыңны индермә, газабың белән һәлак кылма. Һәм безне Үзеңнең җәзаңнан коткар».

Яңгыр явып туктаганнан соң, ошбу доганы укырга кирәк:

**«Мутирна бифадлилләһи вә рахмәтиһи».**

Тәрҗемәсе: «Яңгыр безгә Аллаһның рәхмәтен вә бәрәкәтен алып килде».

Бу сөннәттә билгеле булган кайбер аятьләр һәм догалар гына иде.



## Яңгыр вакытында догалар кабул була

Әбү Давыд хәдисләр җыентыгындагы хәдисләрдән билгеле булганча, яңгыр вакытында догалар кабул була. Шуңа күрә, югарыда санап үтелгән догаларны да, үз телеңдә дә Аллаһтан бәрәкәт, гаилә иминлеге кебек әйберләрне сорау хәерле булыр.

Кайбер илләрдә яңгыр вакытында дога кылу гадәте кереп калган. Шуңа күрә урамнарда, кафеларда да яңгыр яуган вакытта кешеләрнең туктап, Аллаһка ялваруларын күреп була. Аллаһы Тәгалә безгә дә бу мөмкинлекне кулдан ычкындырмаска насыйп әйләсә иде.

■ **Сәхифәне Габделхәким Фәсхиев әзерләде**

### Гашурә бәйрәме

Мөхәррам ае турында
Уйлап караган бармы?
Тарих битләрендә аннан
Бик күп вакыйга калды.

Күкләр, җирләр яратылган,
Таулар хасил булганнар.
Адәм-Хәва халик булган,
Йолдызлар балкыганнар.

Гашурә көн – шушы айның
Иң гүзәл бер бизәге.
Ураза тотып бу көнне,
Гыйбадәт итик әле.

Муса, Гайсә, Нух пәйгамбәр
Котылган көн газаптан.
Чын күңелдән ярдәм сорый
Белгән алар Аллаһтан.

Белеп яшик бәйрәмнәрнең
Нигә кирәк икәнен?
Гыйлем туплап, үзебезгә
Ачыйк җәннәт ишеген.

### Гашурә көн

Гашурә көн туды, һәркем беләә
Бу бәйрәмнең ерак асылын.
Пәйгамбәрләр тарихыннан укып,
Кабул итә шуны акылым.

Нух пәйгамбәр суга батмый, кавем
Явызлыктан шулай котылган.
Муса пәйгамбәр дә фиргавеннән
Бер Аллаһка барып сыенган.

Бәрәкәтле көн ул – Гашурә көн,
Уразага керә кешелек.
Аллаһ ярдәменә таянганнар
Аннан ярдәм көтә иң элек.

Иман нуры булсын күңелләрдә,
Кылган гөнаһ тәүбә ителсен.
Ышанычны саклау бер Аллаһка
Һәр кешегә бәхет китерсен.

### Хаҗ

Хаҗ кылу – олы гыйбадәт,
Көче җиткән кешегә.
Фарыз гамәлләрнең берсе –
Иман китергәннәргә.

Мәккәи Мөкәррәмәдә
Изге йорт – Кәгъбәтуллаһ.
Көче җитеп хаҗ кылуны
Кабулдан кылсын Аллаһ.

Изге йорт, мәчет Әл-Хәрам,
Пәйгамбәр узган җирләр.
Хак юлны тапкан кешегә
Аллаһ рәхмәте иңәр.

Ашыгалар хаҗ кылырга,
Һәр эшнең үз вакыты.
Ният итеп, хаҗ кылулар,
Яшьлектә насыйп булды.

Аллаһтан башка иләһ юк,
Хакимлек һәм аңа дан.
Мөмкинлекне ычкындырма,
Яшь чагында хаҗга бар.

Мең мәртәбә өстенерәк,
Хәрамда кылган намаз.
Хаҗны берни алыштырмый,
Ният итеп куегыз!

Йә, Аллаһым, синең алда,
Хаҗым кылам, кабул кыл!
Гөнаһларымны ярлыка,
Бирче миңа дөрес юл.

Лә иләһә иллә Аллаһ,
Кабулдан булсын намаз.
Раббым ризалыгы өчен,
Хаҗ кылу тиеш, фарыз.

Дөньяда да, ахирәттә
Ирешим рәхмәтеңә.
Аллаһ Раббым, ирештер син
Фирдәвес җәннәтенә.

### Намаз көче

Мин чакырам сине, барасыңмы,
Соңга калма әйткән вакытка.
Кояштан да алда торып һәркөн
Әйдә, дустым, намаз укырга!

Иртәнгесен укып, дога кылгач,
Өйлә туры җитәр карап тор!
Икендене, ахшам һәм ястүне
Калдырмаска һәркем тырышыр.

Намаз уку – туры юлга кайту,
Чын ихласлык булсын сәҗдәдә.
Һәр мөселман өчен олы бүләк –
Гомерләрне итү җәннәтле!

### Бар!..

Туганның да туганлыкны
Туган итмәүчесе бар!
Иң-иң якын дусларның да
Сынаткан чаклары бар!

Сөйгәнем дип йөргән кеше
Яратмыйм дигәне бар!
Үз-үзеңә ышанычны
Югалткан көннәр дә бар!

Кемгә барыйм, кая карыйм,
Сер сөйләрдәй кемнәр бар?
Бу җиһанда мин ышанган,
Ярый, Раббым Аллаһ бар!

### Җомга җиткән

Җомга җиткән, азан ишетелә,
Ашыктырып безне намазга.
Күптән ачык мәчет ишекләре,
Килә алмый торма карарга.

Азан дәшә безне туры юлга,
Сафландырыр вакыт күңелне.
Шау-шулардан туңган йөрәкләрне
Уятыр чак җитте түгелме?

Җомга туры, ыгы-зыгы тынган,
Ачык юллар Раббың каршына.
Кул күтәреп, тиешлесен сора,
Дога кабул булыр чагы ла.

Кешеләрчә булсын яшәвебез,
Без Аллаһка чит-ят түгелләр.
Ашыктыра азан, соңга калмыйк,
Иман белән узсын гомерләр.

■ **Нурфия Халикова,**
**Казан шәһәре**

# ИКЕБЕЗ ДӘ УНӨЧТӘ БУЛСАК...

1933 кытлык ел иде. Тамак алдарлык булса да ярар дип, яз башыннан Акманайга балыкка йөрибез. Алты яшьлек энем Ильясны да ияртәм. Ифрат сабыр бала ул. Көн буе чебенчерки талауга шыңшымый түзә. Кәсебебез уңышлырак булса, учак ягып, ялкында балык өтеп ашыйбыз. Бөтенесен дә түгел әлбәттә. Кот килмәгән көндә бар тотканны өйгә алып кайтабыз. Монда тамак аермыйбыз.

Көн шундый эссе иде. Җилнең әсәре дә юк. Күл өстенең тынычлыгы күңелгә шом сала. Кизәнеп кармак ташлаганда калкавыч кузгаткан дулкын боҗралары әллә кайларга тарала. Ә калкавыч утыра да ката. Җимгә кагылып та караучы юк. Озак көттек, озак түздек. Ак киез эшләпә кигән энем яр читендә зирек күләгәсендә тын гына утыра. Аратирә генә сорап куя: «Капмадымы?» «Юк шул», – дим: «Көн озын бит. Кабар әле», – дип тынычландыра мине сабый.

Төш узды. Тирә-якта кармак салган малайлар, кот эзләп, я Ишбайга, я Былыуга, я Димгә китте. Без калдык. Мин үсмер чакта ук бәхетне куып тотармын дип өмет итмәдем, язганын көтеп алырмын мөгаен дип юандым. Әлбәттә һаманһаман сабыр итеп кенә морадка ирешеп булмыйдыр, хәрәкәттә – бәрәкәт, диләр. Хәер, тәрлечә барып чыгадыр. Чама чамага килеп кенә тормыйдыр.

Ильяс белән без һаман бәхет сыныйбыз. Көн кичкә авышты. Яман черки күтәрелде. «Агай, капмадымы?» – ди энем. Аның соравы минем кәефемне кыра, әмма аңа ачуланмыйм. «Хәзер, хәзер каба», – дип ышандырам. Шулай дип әйтүем булды, зур кармагымның калкавычы чак кына кузгалып куйды да, капыл төпкә батты. Тарта башладым. Авыр, шулай да тартыла. Кылдан тотып җай гына үземә савам. Килә. Карышмый. Ярга җитәрәк кенә бер сикереп куйды. Ләкин башкача дуламады. Дуласа да, дүрттән ишелгән айгыр кылы бирешерлек түгел, ныклы. Кармагы да чын корыч кармак. Сатунык. Саплы агач соскыдан да озынрак алтын сары корбан балыгы үлән өстенә чыгып ятты. Шундый симез, хәтта тыпырчынырга да иренә. (Кайткач бизмәнгә салып карадык, дүрт кадакка якын тартты). Мондый гыйфрит миңа моңа тикле дә, моннан соң да эләкмәде. Ильяс якын килергә дә курка. «Бу балыкмы, агай?» – ди. «Балык. Корбан исемле». Ул шунда ук тезеп китте: «Безнең күрше Корбан. Безнең балык корбан».

Мин тиз генә кармакларны урадым да, балыкны капчыкка салып алдым. Кайтырга уңайладык. Ильяс дәртләнеп, башта бик ихлас атлады. Алабугалы үрен дә бик елдам менде. Юкәлекул урманына җиткәч ач бала хәлдән тайды. «Чак кына утырып торыйк әле, агаем», – диде.

Корбан миңа чиксез дәрман бирде. Утырып тору кая ул! Ильясны иңемә күтәреп алдым. Урам очына килеп җиткәч ул янә җанланып китте. Хәл керде булыр. «Их, агаем, – диде ул рухланып, – нигә икебез дә унөчтә түгел икәнбез? Икебез дә унөчтә булсак күтәрешеп кенә йөрер идек. Бөртек тә арымас идек».

Энем инде күптән дөнья куйды. Мин торып калдым. Кайчак үкенеп тә куям: нигә аны шулай ешрак күтәреп йөртмәдем икән? Хәтта арымаган чакларында да... мин бит һәрвакыт аңа караганда өлкәнрәк, көчлерәк булдым.

Кешеләр бер-берсен ешрак күтәрешсәләр, үкенечләре әзрәк калыр иде...

■ **Мостай Кәрим**

# «Хозур» нәшрият йорты кече форматта Коръән китабын бастырып чыгарды



Бу китап Коръән хафизлар, Коръән фәне белгечләреннән торган фәнни комиссия әгъзалары катнашында әзерләнде. Комиссия составына Мисыр галиме, шәригать фәннәре белгече шәех Хәсән Һәдия һәм күренекле Төркия галиме Таяр Алтынкулач кебек белгечләр керде. Кәлам Шәриф китабы халыкара стандартларга туры килүе турында Сүриянең вакфлар министрлыгы Шәһадәтнамәсенә ия. Китаптагы тамгалар саны да Госман хәлифә тарафыннан кабул ителгән стандартка туры килә (Расм Әл-Госмания). Шунысы да билгеләп үтәргә кирәк, Коръән китабының бизәлешен ясаганда үз вакытында Галимҗан Баруди нәшер иткән Коръән китабына таянылды.

**Китапны http://huzurshop.ru сайтыннан яки Казан шәһәре, Газовая урамы, 19 нчы йорт (РИИ бинасы) адресы буенча урнашкан кибеттән алырга мөмкин.**

**Телефон: +7 (903) 305-45-43**

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

«ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ» ГАЗЕТАСЫНА
2018 елның икенче яртысына язылу башланды

- Газета айга бер тапкыр чыга
- Ярты елга язылу бәясе: 132 сум
- Язылу индексы: П4333
- Түбәндәге сайтларда да язылу мөмкин: podpiska.pochta.ru һәм uslugi.tatarstan.ru сайтының «Подписка» бүлегендә.

Белешмәләр өчен телефон: 598 09 42




## КАЗАН ӨЧЕН СЕНТЯБРЬ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | |
| 01.09.2018 | 02:21 | 03:17 | 04:47 | 12:00 | 16:23 | 18:38 | 20:33 |
| 02.09.2018 | 02:24 | 03:19 | 04:49 | 12:00 | 16:21 | 18:35 | 20:29 |
| 03.09.2018 | 02:27 | 03:21 | 04:51 | 12:00 | 16:19 | 18:33 | 20:26 |
| 04.09.2018 | 02:31 | 03:23 | 04:53 | 12:00 | 16:17 | 18:30 | 20:22 |
| 05.09.2018 | 02:34 | 03:25 | 04:55 | 12:00 | 16:15 | 18:27 | 20:19 |
| 06.09.2018 | 02:37 | 03:27 | 04:57 | 12:00 | 16:13 | 18:25 | 20:16 |
| 07.09.2018 | 02:40 | 03:29 | 04:59 | 12:00 | 16:11 | 18:22 | 20:13 |
| 08.09.2018 | 02:43 | 03:31 | 05:01 | 12:00 | 16:09 | 18:20 | 20:09 |
| 09.09.2018 | 02:46 | 03:32 | 05:02 | 12:00 | 16:07 | 18:17 | 20:06 |
| 10.09.2018 | 02:48 | 03:34 | 05:04 | 12:00 | 16:05 | 18:14 | 20:03 |
| 11.09.2018 | 02:51 | 03:36 | 05:06 | 12:00 | 16:03 | 18:12 | 20:00 |
| 12.09.2018 | 02:54 | 03:38 | 05:08 | 12:00 | 16:01 | 18:09 | 19:57 |
| 13.09.2018 | 02:57 | 03:40 | 05:10 | 12:00 | 15:59 | 18:07 | 19:54 |
| 14.09.2018 | 02:59 | 03:42 | 05:12 | 12:00 | 15:57 | 18:04 | 19:50 |
| 15.09.2018 | 03:02 | 03:44 | 05:14 | 12:00 | 15:54 | 18:01 | 19:47 |
| 16.09.2018 | 03:05 | 03:46 | 05:16 | 12:00 | 15:52 | 17:59 | 19:44 |
| 17.09.2018 | 03:07 | 03:48 | 05:18 | 12:00 | 15:50 | 17:56 | 19:41 |
| 18.09.2018 | 03:10 | 03:50 | 05:20 | 12:00 | 15:48 | 17:53 | 19:38 |
| 19.09.2018 | 03:12 | 03:52 | 05:22 | 12:00 | 15:46 | 17:51 | 19:35 |
| 20.09.2018 | 03:15 | 03:54 | 05:24 | 12:00 | 15:43 | 17:48 | 19:32 |
| 21.09.2018 | 03:17 | 03:56 | 05:26 | 12:00 | 15:41 | 17:45 | 19:29 |
| 22.09.2018 | 03:20 | 03:58 | 05:28 | 12:00 | 15:39 | 17:43 | 19:26 |
| 23.09.2018 | 03:22 | 04:00 | 05:30 | 12:00 | 15:37 | 17:40 | 19:23 |
| 24.09.2018 | 03:24 | 04:01 | 05:31 | 12:00 | 15:35 | 17:38 | 19:20 |
| 25.09.2018 | 03:27 | 04:03 | 05:33 | 12:00 | 15:32 | 17:35 | 19:18 |
| 26.09.2018 | 03:29 | 04:05 | 05:35 | 12:00 | 15:30 | 17:32 | 19:15 |
| 27.09.2018 | 03:31 | 04:07 | 05:37 | 12:00 | 15:28 | 17:30 | 19:12 |
| 28.09.2018 | 03:34 | 04:09 | 05:39 | 12:00 | 15:26 | 17:27 | 19:09 |
| 29.09.2018 | 03:36 | 04:11 | 05:41 | 12:00 | 15:23 | 17:24 | 19:06 |
| 30.09.2018 | 03:38 | 04:13 | 05:43 | 12:00 | 15:21 | 17:22 | 19:03 |

**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**
*Август саны, №8 (277)*

Баш мөхәррир: **Сәмигуллин К. И.**
Мөхәррир: **Шафикова Р. Р.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;
ТР МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБӘРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2752
Газетага ярты елга язылу бәясе – 132 сум. Казан шәһәренең мәчетләрендә 20 нче августта таратыла.
График буенча бу санга 17 нче август көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.